ҖЫЛЫ СҮЗ

Онколог Фоат Әхмәтҗанов начар чир белән көрәшүнең үтемле ысулларын әйтте

> 4



ҺӨНӘРЧЕЛӘР АВЫЛЫ

Балык Бистәсенең Яңа Сала авылында яшәүчеләр читтән оста чакыртмыйлар

> 5

БЕРӘГӘЙЛЕ БЕР

Татарстан демографиясендә тагын нинди тенденция күзәтелә?

> 6

РУШАНИЯ НИЗАМОВА:

«Укучыны яшьтәшләре алдында кимсетергә ярамый»

> 8

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 12–13 (29172–29173) | Сишәмбе | 30 гыйнвар | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

2024 гаилә елы

МӘХӘББӘТЛЕ ЙОРТ

Юк инде, мондый гүзәл ханым берничек тә биш бала әнисе була алмый! Раушания Закирова белән танышуга башка килгән тәүге уй бу. Зар белми, йөзеннән елмаю китми. Төннәрен йокламыйча, үзе турында онытып, бала чүпрәге юып кына яшәгән кешегә һич кенә дә охшамаган ул. Күпбалалы гаиләнең җылы учагын саклаучы ханым белән гаилә һәм тәрбия турында сөйләштек.

ЯЗМЫШ. Әңгәмәдәшебез Мурманск өлкәсенең Заполярный шәһәрендә туып-үскән. Балачакта барысы да кешенекечә була инде: мәктәп, иҗади түгәрәкләр, актив тормыш, тырышып уку. Иҗат дигәнең 1998 елда Казанга алып килә Раушанияне. Музыка училищесына укырга керә төньяк кызы. Раушаниягә татар сәнгате, мәдәниятенә, милли моңнарга карата мәхәббәтне остазы Венера Гәрәева сеңдерә. Училище тәмамлагач, белем эстәвен дәвам иттерә Раушания: педагогика университетының музыка факультетына укырга керә.

МӘХӘББӘТ. Мөдәррис. Раушаниянең йөрәге түренә чигелгән исем бу. Менә дигән ир, менә дигән әти, менә дигән кеше! Хәзер Мөдәррис Закиров «Татавтодор»да машина йөртүче булып эшли. Тырыш, җаваплы, төпле, диләр аның турында. Раушанияне исә бөтенләй башка сыйфаты белән үзенә караткан.

– Мөдәррис белән без уртак танышларыбызның туган көнендә таныштык. Мин аңа шундук игътибар иттем. Бигрәк тә аның балаларга булган мөнәсәбәтен күреп гаҗәпләндем. Аның: «Балалар – бәхет», – дигән сүзе хәтердә уелып калды. «Мондый кешегә таянырга, ышанырга була икән!» дигән уй йөгереп үтте башымнан, – дип искә ала мәхәббәт гөленең әле бөреләнгән генә чакларын әңгәмәдәшебез. Инде менә бергә гаилә корып яшәүләренә 12 ел булган.

Закировлар Арчада яши. Әңгәмәдәшебез өчен бөтенләй чит як түгел икән ул. Балачакта җәйләрен шунда үткәргән, туганнары шунда яшәгән. Тамырлары тартып китергән диярсең… Раушания Закирова хәзерге вакытта Арча шәһәрендә балалар бакчасында музыка җитәкчесе булып эшли, лицейда белем бирә.

БАЛАЛАР. Камилә, Данил, Айсылу, Асилә, Рәмис… Раушания белән Мөдәрриснең мәхәббәт җимешләре бу. Ягымлы-назлы кызларыннан да, булышчы, нәсел дәвамчысы булырдай улларыннан да уңганнар! Балалары турында сөйләп туя алмый әңгәмәдәшебез.

Бер-бер артлы туган балалар әниләренә үзендә яңа сәләтләрен ачыкларга ярдәм иткән бит әле. Әнә, Айсылу дөньяга аваз салгач, Раушания ханым көйләр яза башлаган. Рәмис тугач, тегәргә өйрәнгән. Әнә шулай бер-берләрен тулыландырып, бер-берләренең уңышларын күреп яши Закировлар.

– Мин – бик бәхетле әни. Олы кызыбызга – 19 яшь. Ул Казан музыка училищесында укый. Быел диплом алачак. Балачактан ук җырга-моңга, биюгә, сәнгатькә гашыйк иде. Җиңүләре исәпсез-хисапсыз! Консерваториягә укырга керергә җыена. Улыбыз Данилга – 17 яшь. Ул да сәнгать юлын сайлады. Хореография училищесының 1 курсында укый. Опера театрындагы тамашаларда да катнаша, – ди Раушания Закирова. – Айсылуыбызга – 10 яшь. Кызыбызда актерлык сәләте көчле. Асиләбезгә – 5, Рәмискә – 3 яшь. Алар балалар бакчасына йөри.

ГАИЛӘ БӘХЕТЕ. Бала тәрбиялисең килсә, үзеңнән башла! Закировлар гаиләсендәге төп кагыйдә әнә шул. Әни үзенә дә вакытны кызганмаска, үзен камилләштерүдән туктамаска тиеш.

– Гаиләдә үзара хөрмәт булырга тиеш. Ата-ана баласының фикеренә колак салырга кирәклеге турында онытмасын иде, – ди әңгәмәдәшем. – Бер баламы, ун баламы – хатын-кыз үзе турында онытырга тиеш түгел. Кайчагында хатын-кызга үзен канатлы итеп тою өчен бер матур сүз дә җитә! Хатын-кызга үзе яраткан эштә эшләү дә бик мөһим. Шөкер, мин шундый җирдә эшлим. Үзен яраткан, күңеле тыныч булган әнинең балалары да шундый булачак. Уңай энергияне мин өйгә алып кайтам. Өйдәге мохит хатын-кыз кәефеннән тора.

Бәхетле гаиләнең бөтен кешегә дә туры килә торган уртак рецепты юк, ди әңгәмәдәшебез. Тик нигезендә ята торган төшенчәләр бер: аңлашу һәм сабырлык.

МӨНӘСӘБӘТ. Сер түгел, күпбалалы гаиләләргә карата җәмгыятьтә төрле фикер яши. Кайсылары: «Бу кадәр бала кирәк идеме? Нәрсәгә дип тапканнар?» – дияргә дә күп сорамас. Раушания ханым да мондый фикер барлыгын яшерми. Әммә, шөкер, үз гаиләләренә карата кырын караш тойганнары юк.

– Күпбалалы гаилә буларак, андый мөнәсәбәткә юл да куймыйбыз, сәбәп тә бирмибез, – ди ул. – Гаиләдә кыенлыклар туа икән, аны яшерергә кирәкми. Ярдәм сораудан курыкмасак иде. Акчалата ярдәм турында түгел сүз. Юридик, психологик… Минем хыялым да бар: үзебездә әнә шундый үзәк булдырасы килә! Гаиләләр кирәкле ярдәм алыр, соңрак исә үзләре үк башкаларга булышуда катнашыр иде.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Раушания Закированың шәхси архивыннан

Раушания һәм Мөдәррис Закировлар гаиләсе күптән түгел «Ана даны» медаленә лаек булды. Казан Кремлендә узган бәйрәм чарасында аларга һәм башка үрнәк гаиләләргә бу бүләкне Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов тапшырды.

Владимир ПУТИН, Россия Президенты:
– Дәүләт сәясәте үзәгендә гаилә булырга тиеш. Без шулай эшләргә тырышабыз да. Күпбалалы гаиләләр саны артырга тиеш. Соңгы елларда күпбалалы гаиләләр саны 26 процентка артты. Бу – яхшы күрсәткеч. Бүген кайбер илләрдә гаилә институты һәм традицион кыйммәтләр җимерелә, ул ясалма кыйммәтләргә алыштырыла. Ә безнең Россия ул – зур гаилә, анда гасырлар дәвамында төрле милләт кешеләре тату яши, ә мәдәниятләрнең күптөрлелеге илне ныгыта гына.

(Гаилә елын ачуга багышланган тантанадан)

Урманнар калыная

Быел Татарстанда барлыгы 2564 гектар мәйданда урманнарны торгызу күздә тотыла. Бу эш «Экология» илкүләм проектының «Татарстан Республикасында урманнарны саклау» төбәк проекты буенча башкарылачак.

Урман хуҗалыгы министры Равил Кузюров әйтүенчә, быел республикада, «Экология» илкүләм проектында каралган эшләрдән тыш, кырларда саклагыч урман полосалары утыртылачак һәм «Хәтер бакчасы», «Урманнарны саклыйк» табигатьне саклау акцияләре оештырылачак. Министр сүзләренә караганда, әлеге бурычларны үтәү өчен урман тармагы белгечләре 34,1 миллион данә агач үсентесе әзерләгән.

Шулай ук Татарстанда ел дәвамында урманнарда барлыгы 12880,4 гектар мәйданда агротехник чаралар уздырылачак, 3893,6 гектар мәйданда агачлар утыртылачак, питомникларда 21,4 гектар мәйданда орлык чәчү эше башкарылачак.

Исегезгә төшерәбез: илкүләм проектлар Россия Президенты Владимир Путин тәкъдиме белән 2019 елдан бирле тормышка ашырыла. Аларны быел төгәлләү күздә тотыла.

Казнаны баеталар

Татарстан суд приставлары, узган елдан башлап, төбәк бюджетына барлыгы 16,8 миллион сум күләмендә салым түләтергә ярдәм иткән. Шушы чорда бурычлыларның 143 мөлкәтенә арест салынган.

Суд приставлары хезмәтенең Татарстандагы идарәсе матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, бурыч түләнмәгән очракта, приставлар милеккә арест салырга мөмкин. Мөлкәттән файдалануны тыюны яки чикләүне, шулай ук, кирәк булганда, аны хуҗасыннан тартып алуны күздә тота бу.

Сыйфаты һәм бәясе ничек?

Узган елда Татарстан Дәүләт алкоголь инспекциясе хезмәткәрләре, бәяләрне «бәйдә» тоту өчен, беренче чиратта кирәкле 24 төрдәге азык-төлек хакын атна саен күзәтеп-барлап торган. Ведомствоның эчке базарны үстерү һәм координацияләү бүлеге җитәкчесе Розалия Арсланова әйтүенчә, ай саен 181 атамадагы азык-төлек бәясенә дә мониторинг үткәрелгән. Аерым алганда, 2023 елда сыер, сарык, тавык ите, балык, атланмай, сөт, йомырка кебек социаль әһәмиятле товарларның бәяләре өйрәнелгән. Халыктан алынган 2,5 мең чамасы шикаять каралган. Аларның күпчелеге сәүдә һәм көнкүреш хезмәтләре өлкәсенә кагылышлы булган.

Ведомство җитәкчесе Җәүдәт Әхмәтханов билгеләп үткәнчә, җитештерелә торган продукциянең сыйфаты торган саен начарая. Ул кибет киштәләрендә еш кына ялган продукциянең ачыклануын, шуңа күрә азык-төлек сыйфатын һәм бәясен күзәтүнең өстенлекле бурыч булып калуын әйткән.

Табигать кыланмышы

Карлы сынау

Кыш башланганнан бирле башкала урамнарыннан 1 миллион тоннага якын кар чыгарганнар. Быелтыр кыш буе да бу кадәр кар яумады, дип хисап тоттылар Казан мэриясендә. Узган атнадагы көчле бураннан соң җыештыру эшләре дәвам итә. Тик юл газабы гүр газабына әйләнгән шәһәр халкына моннан ни файда? Эш атнасы кабат тугыз баллы «бөке»ләрдән башланды әнә. Ә ишегалдына көрәк тотып чыгучыларны бүләкләмәкчеләр хәтта. Бураннан соң тормыш бармы?

Узган атнада ишеп яуган кар җитә калды: Казан урамнары тоташ бер «бөке»гә әйләнде, автобус-троллейбусларда – этеш-төртеш, кибеттә ипи-сөт юк. Буран тынганга да бер атналап вакыт узды инде, тик рәткә керә алмыйбыз әле.

– Казанда «Буран» операциясе дәвам итә. Кыш башланганнан бирле шәһәр урамнарыннан 950 мең тонна кар чыгарылды. Шуның яртысы диярлек соңгы ике атнага туры килә. Быелтыр кыш буе да бу кадәр кар яумады, – дип сөйләде шәһәр мэриясендә узган «эшлекле дүшәмбе»дә Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Игорь Куляжев.

Казанда 17–21 гыйнвар көннәрендә булган буран – соңгы биш елда иң көчлесе. Гыйнвар аенда башкалада айлык норманың 175 проценты күләмендә кар яуган. Шуңа күрә бу арада коммуналь хезмәткәрләрнең хәле мактанырлык түгел: юлларны чистарту эшендә 1,1 меңнән артык техника, 800ләп эшче катнаша. Кар эретү пунктларына тәүлегенә 12 мең тоннадан артык кар (гадәти вакытта җитештерүчәнлек тәүлегенә 8 мең тонна тәшкил итә. – **Ред.**) озаталар. Ишегалларын 1,5 меңнән артык урам себерүче тәртипкә китерә. Ләкин халыктан килеп ирешкән шикаятьләр саны кимеми.

– Мамадыш трактын кардан чистартучы бер генә техника да күренми. Буранлы көннәрдә дә, хәзер дә иртә-кич икешәр сәгать «бөке»дә утырабыз. Ул юл турында онытканнармы әллә? – дип шалтыратты газета укучыбыз.

Мамадыш тракты шәһәрнең Совет районына керә. «Биредә техника эшли. Мамадыш трактыннан кар һәр төн саен чыгарыла», – дип бик коры гына җавап бирделәр район администрациясенең матбугат хезмәтендә. Эшләре күп, сөйләшерлек тә хәлләре калмаган, күрәсең.

Казанның Ямашев проспектындагы 51 нче йортта яшәүчеләр дә буран башланганнан бирле ишегалдында кар эттерүче трактор күрмәгән.

– Машиналар гомумән дә йөри алмый, аларны еракта ук, юл читендә куеп калдырырга туры килә. Чүпне дә чыгармыйлар, – дип хәбәр иттеләр редакциягә.

Ахыры 3 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Сергей ДАНКВЕРТ, Россельхознадзор башлыгы:

Бүген нинди дә булса товарга карата кызыксыну арткан икән, бу әле фермер аны тиз генә җитештерәчәк дигән сүз түгел. Сорау арта икән, тора-бара җитештерү күләме дә артачак. Әмма моңа вакыт кирәк.

(«Российская газета»дан)

РОССИЯДӘ – СТУДЕНТЛАР

БАРЛЫГЫ

Ил вузларында укучылар – **4,3 млн кеше**
Шуларның **47 проценты** бушлай укый

ПОПУЛЯР ЮНӘЛЕШЛӘР

Юриспруденция – **350 мең кеше**
Педагогика – **332 мең кеше**
Икътисад – **227 мең кеше**

ИҢ КҮП СТУДЕНТЛАР КАЙДА?

Мәскәү – **930 мең кеше**
Санкт-Петербург – **332 мең кеше**
Татарстан – **148 мең кеше**

Тотылганы кыйммәтләнгән

Узган елда Татарстанда тотылган машиналар бәясе ике тапкыр артып, 565 мең сумнан 1,16 миллион сумга җиткән. Росстат мәгълүматларына караганда, рәсми инфляциядән (7,1%) 14 тапкыр зуррак сан бу.

2023 елда мондый «корыч ат»ларның хакы яңаларыныкыннан тизрәк үскән. Үзебездә җитештерелгән яңа «авто» бәясе 33 процентка артып, 1,18 миллион сумга, «иномарка»лар 27 процентка артып, 2,33 миллион сумга җиткән.

«Россия автомобиль дилерлары» ассоциациясе мәгълүматларына караганда, тулаем ил буенча бер ел эчендә (2023 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 1 гыйнварына кадәр) үзебездә эшләп чыгарылган яңа машиналарның уртача хакы 44 процентка үсеп, 1,25 миллион сум, Кытай машиналарыныкы 30 процентка үсеп, 3,25 миллион сум тәшкил иткән. Гомумән, 2021 елдан машинаның уртача бәясе 47 процентка артып, 2,9 миллион сум булган.

Россия күләмендә дә тотылган машиналарның уртача бәясе, Татарстандагы кебек, яңаларыныкына караганда тизрәк үскән. 2023 елда мондый автомобильләр бәясе 2021 елдагы белән чагыштырганда 65 процентка үсеп, 1,3 миллион сумга җиткән.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

«ИДЕАЛЬ ШТОРМ» КУРКЫТА

Үткән атнаның дөньякүләм вакыйгалары без яшәгән планетада «идеаль шторм» башланып килүен дәлилләр. Глобаль капитализмның нигезе чатный, аның төп терәге булган Америкада аздан гына Гражданнар сугышы башланмый калды. Киеренкелек берникадәр йомшарса да, куркыныч әле дә үтеп бетмәгән. Техас – Вашингтон конфликтына бу язмада тукталмыйм, чөнки махсус язма әзерлим.

Вакыйгаларның иң кызуы, әлбәттә, Якын Көнчыгышта бара. Без күптән әйтеп киләбез: кешелекнең киләчәге шул төбәктә хәл ителәчәк. Якшәмбедән дүшәмбегә каршы төн безнең ул фаразның хаклыгын раслаучы вакыйгаларга бай булды. Янкилар Йәмәнне күпме генә утка тотмасыннар, Кызыл диңгез Көнбатыш һәм Израиль кораблары өчен каберлек булудан туктамады. Фарсы култыгында да эшләр шәп түгел. Бу юлларның авторына берничә минут элек кенә (дүшәмбе таңы сызылып килгәндә язам боларны) «Иранның Ислам революциясен саклаучылар корпусы Фарсы култыгында Австралиянең нефть танкерын, экипажның 14 әгъзасын да әсир итеп, кулга алды» дигән хәбәр килде. Дүшәмбегә каршы төндә исә бөтен Якын Көнчыгыш кайнап карады да соң! Анда барган хәлләр минуты-сәгате белән океан артында даһшәтле кайтаваз биреп торды. «Американың Иорданиядәге хәрби базасына беспилотник һөҗүме нәтиҗәсендә АКШның өч хәрбие һәлак булды, егерме бише зыян күрде» дигән хәбәр якшәмбе кичендә сәгать тугыз туларга унҗиде минутта килгән иде. Эль-Җәзира америкаварның югалтулары зуррак саннар белән бәяли: 25тән артык солдат теге дөньяга китеп барды, ди.

Вашингтонда ул хәбәр таралгач, гасабилану башланды. Һөҗүмне оештыручы дип Иран аталды. Кичекмәстән фарсыларга ут ачарга чакырулар яңгырады. Янкилар үтерү хокукы бары тик аларга гына бирелгән дип саный, шуңа күрә үз югалтуларын чиктән ашкан хәл буларак бәяләде. Эфирны «үч алырга» дигән белдерүләр тутырды. Трамп вазгыятьне: «Иорданиядәге безнең көчләргә һөҗүм безнең ил өчен коточкыч көн булып тора, шуңа өстәп Байденның зәгыйфьлеге һәм капитуляциясе нәтиҗәсе дә», – дип бәяләде. Сенаторлар белән хәрбиләр ярсыйлар һәм дулыйлар, зур сугышка чакыру куәтле хәрәкәт ала. Байден якындагы сәгатьләрдә хәлиткеч һәм мөһим карар кабул итәргә тиеш.

Каршы як та йоклап ятмый. Иран төнлә үк һава һөҗүменнән саклану көчләрен сугышчан әзерлек хәленә китерде. Гыйракның Ислам каршылыгы вәкиле «Washington Post» газетасына: «АКШ Израильгә ярдәмен дәвам итсә, киеренкелек көчәячәк. Төбәктәге барлык Америка элементлары безнең өчен законлы һөҗүм итү объекты булып тора. АКШның үч алу белән янаулары безне дулкынландырмый», – дип белдерде.

Төбәктәге вакыйгаларның бер өлеше генә әле бу. Бөек вакыйгалар давылы оешып килә.

Россиядә

БЕЗДӘ ӘЛЕ ЯРЫЙСЫ

Көнчыгыш белән Көнбатыш уртасында яшәгән Россиядә хәлләр чагыштырмача ярыйсы. Вазгыять мәшһүр: «...дела в колхозе шли плохо. То есть не так чтобы очень плохо, можно было бы даже сказать – хорошо, но с каждым годом все хуже и хуже», – дигән афоризмга охшаган. Безнең фермерлар, Европаныкылар кебек, шәһәр урамнарына сарык култәреп куып китермиләр, полиция машиналарына тирес сыекчасы да сиптереп йөрмиләр. Йомырка кризисы да узып бара диярлек. Ул хәзер Европа илләрен дер селкетә. Дөрес булса, Вильнюста йомырка бәясе күккә табаашып бара, диләр. Бу проблемаларның утраклыгын, Россиянең дә глобаль капитализмның бер состав өлеше булуын дәлилли. Шуңа күрә иртәме-соңмы дөньякүләм проблемалар бездә дә баш калкытачак.

Белгечләр: «Тавык йомыркасына бәйле проблемалар – Россиянең авыл хуҗалыгындагы зур проблемаларның маягы ул», – диләр. Үткән елның гыйнвар – октябрь айларында авыл хуҗалыгына инвестицияләр 4 процентка кимегән. Чагыштырыгыз: эшкәртүче сәнәгать тармагында шул ук чорда инвестицияләр – 12, нефть чыгару тармагында 15 процентка үскән. Быел ук берничә азык-төлек кризисы булачак, дип фаразлаучылар бар.

Төзелеш өлкәсендә барысы да ал да гөл булып күренсә дә, чынлыкта алай ук түгел. Акрын гына без дә Кытай артыннан барабыз. Төзелгән фатирларның бик аз өлеше сатыла. Икенчел торак базары да кризис алдында. «Бизнес-онлайн» электрон басмасы «Падение вторички – цветочки. Рынок жилья Казани ждет тотальная перестройка!» дигән аналитик язма бирде. Шуңа тагын бер фактны өстик: банклар проблемалы ипотека кредитларын каплау өчен залогка салынган фатирларны сату темпларын 1,5 тапкыр арттырганнар. Гади телгә күчерсәк, ипотеканы түли алмаучылар саны кискен темплар белән үсә дигән мәгънә чыга.

Инвестицияләр никадәр генә артмасын, нефть тармагы да үзен бик үк әйбәт хис итми. Бердән, Һиндстанга озатылган Сахалин нефте диңгездә танкерларда ял итә. Дәһли кара алтын бәясен түшәм бәягә төшерүне таләп итә. Икенчедән, Путин куйган максат – нефть компанияләренең импорт җиһазларга бәйлелеген бетерергә дигән боерык үтәлерлек түгел.

Халык нәрсәләрдән шикләнә: кәгазь акчаларга ихтыяҗ арткан, димәк, акчаның банкта саклануына ышанмый.

РӘСМИ ТАТАРСТАН

tatarstan.ru

ЗУР ЭШ АЗДАН БАШЛАНА

Башкалада яңа тәкъдим-проектлар турында фикер алыштылар. Татарстанда ВЭБ.РФ дәүләт корпорациясе һәм Стратегик инициативалар агентлыгы «десант»ы булып китте. Хөкүмәт йортында узган чарада, Әлмәткә туристлар җәлеп итү турында да сөйләштеләр.

Татарстан Министрлар Кабинетында Стратегик инициативалар агентлыгы һәм ВЭБ.РФ дәүләт корпорациясе белән хезмәттәшлек мөмкинлекләренә багышланган эшлекле чаралар узды. Аларда Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, ВЭБ.РФ рәисе Игорь Шувалов, Стратегик инициативалар агентлыгы генераль директоры Светлана Чупшева да катнашты. Рөстәм Миңнеханов кунакларга уртак хезмәттәшлек һәм стратегик сессия үткәрү урыны итеп республиканы сайлаулары өчен рәхмәт белдерде.

– Ике арада яхшы мөнәсәбәтләр тарихы бар, – диде Рөстәм Миңнеханов ВЭБ.РФ белән хезмәттәшлек турында.

Ул моношәһәрләргә ярдәм итү юнәлешендәге уртак эшкә дә аерым тукталды. «Бу – зур проект, аны гамәлгә ашыру барышында моношәһәрләрдә 18 мең эш урыны барлыкка килде, 56 миллиард сум күләмендә шәхси инвестицияләр җәлеп иттек», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Татарстан Рәисе ВЭБ.РФ ярдәме белән республикада өч мәктәп төзелүен искәртте. Сүз дәүләт-шәхси хезмәттәшлек турында бара. Билгеле булганча, узган ел бер елдан да кимрәк вакыт эчендә Казанда, Чаллыда һәм Арчада 3,5 мең урынга исәпләнгән өч уку йорты төзелде. Алар 1 сентябрьдә үз ишекләрен ачты.

– Безнең хезмәттәшлек бик күп еллар дәвам итә. Татарстан зур юл үтте һәм бу мөмкинлекләр мәсьәләсе генә түгел. Без бүген бөтен мөмкинлекләрдә тулысынча тормышка ашырыла дип әйтә алабыз. Без катнашкан һәм сез башлап җибәргән уртак проектлар өчен бик зур рәхмәт, – диде Игорь Шувалов.

Светлана Чупшева сүзләренә караганда, Стратегик инициативалар агентлыгының барлык проектлары – төгәлләре дә, хәзер тормышка ашырылучылары да Рөстәм Миңнеханов катнашында эшләнә. Ул Татарстанга һәрвакыт рәхәтләнеп килүен дә әйтте.

– Нәкъ менә шундый чараларда, очрашуларда яңа стратегик инициативалар һәм проектлар туа, без аларны Күзәтчелек советында илебез җитәкчелегенә, илебез Президентына, Күзәтчелек советы рәисенә тәкъдим итәбез, – диде агентлык җитәкчесе.

Аның әйтүенчә, 12 ел эшләү дәверендә бер генә проект та, бер генә тәкъдим дә җавапсыз калмаган. Алар тормышта үз юлын тапкан, зур федераль программаларга әверелгән. «Әлеге программалар тормышыбызны яхшы якка үзгәртүгә хезмәт итә», – диде Светлана Чупшева.

Сөйләшү барышында яңа фикер-тәкъдимнәр дә яңгырады. Аерым алганда, якын киләчәктә Әлмәт республиканың көньяк-көнбатышының туризм үзәгенә әверелергә мөмкин. Район башлыгы Тимур Ногуманов ВЭБ.РФ дәүләт корпорациясе катнашында оештырылган «Кунакчыл шәһәрләр» укыту программасында катнашулары турында сөйләде.

– Беренче карашка, туризм Әлмәт өчен ят күренеш кебек. Бу юнәлештә үзебезне күзләре ачылып кына килүче песи балалары кебек сизәбез. Безнең өчен алега барысы да сәер, – дип хис-кичерешләре белән уртаклашты ул. – Уку барышында Әлмәтнең туристларга күрсәтерлек нәрсәләре бар икәнен аңладык.

Татарстанда яңгыраган фикер-тәкъдимнәрне куәтләп, Игорь Шувалов, республикада башланган бөтен эш тә һәрвакыт азагына кадәр җиткерелә, дип ассызыклады. «Бездә бер генә тәмамланмаган проект та юк. ВЭБ.РФнең Татарстан белән барлык проектлары да уңышлы», – диде ул.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Хәтер сагында

Дәүләт Советында

Санкт-Петербургта Бөек Ватан сугышы елларында Ленинградның фашист блокадасыннан тулысынча азат ителүенә 80 ел тулуга багышланган чараларда Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин җитәкчелегендәге Татарстан делегациясе дә катнашты.

Ленинград янында сугышкан геройларның батырлыгы, дошман боҗрасында калган халыкның батырлыгы һәм ныклыгы истәлегенә тантаналы чаралар Пискарев мемориаль зиратындагы «Ватан-ана» монументына венок һәм чәчәкләр салу тантанасыннан башланды. Нәкъ менә 1939 елда ачылган Пискарев зираты Бөек Ватан сугышы вакытында төп күмәк җирләү урыннарының берсе була. Туганнар каберлегендә ачлыктан, салкыннан, уттан һәм бомбага тотудан һәлак булган йөзләрчә мең Ленинград кешесе, шулай ук шәһәрне саклаган дистәләгән мең солдат ята.

«Бүген бөтен Россиядән, чит илләрдән килгән делегацияләр Санкт-Петербургның Пискарев зиратында җыенучыларне, бу шәһәрнең геройларын искә алдылар, аларга хөрмәт күрсәттеләр», – диде Фәрит Мөхәммәтшин. Парламент башлыгы искә төшергәнчә, сугыш елларында республикага күпсанлы ленинградлылар эвакуацияләнгән, Төньяк башкаладан Казанга эре предприятиеләр күчерелгән. «Татарстан җитәкчелеге республикада яшәүче блокадачылар белән даими элемтәдә тора, аларга һәртөрле ярдәм күрсәтелә», – дип басым ясады Фәрит Мөхәммәтшин.

– Авыр елларда Ленинградны яклаган, камалышта һәлак булган тыныч халыкны хөрмәт һәм ихтирам белән искә алу – бүгенге һәм киләчәк буыннарның изге бурычы. Безнең максат – ленинградлыларның батырлыклары турында истәлекне киләчәк буыннарга тапшыру».

Хәзерге вакытта Татарстанда «Блокадалы Ленинградта яшәүчегә» билгесе белән бүләкләнгән 87 ветеран яши, республикабызның 5 кешесе «Ленинградны саклаган өчен» медале белән бүләкләнгән. Эвакуацияләнгән ленинградлылар Казанга 1941 елның җәендә, блокадага кадәр үк килә башлыйлар, ә инде 1941–1942 еллар кышында безнең республика башкаласына Ладога күле буйлап эвакуацияләнгән кешеләр төялгән эшелоннар җибәрелә.

Сайлау – 2024

Ил көче

«Бердәмлектә көч – Россия өчен тавыш бирәбез!» Быелгы Президент сайлау шигаре әнә шундый булачак. Бу хакта Үзәк сайлау комиссиясе рәисе Элла Памфилова хәбәр итте. Сайлау кампаниясенең тагын нинди яңалыклары бар?

- Россия төбәкләрендә, шул исәптән Татарстанда да, Президент сайлауда «Мобиль сайлаучы» системасы аша тавыш бирүгә гаризалар кабул ителә башлады. Гаризаны республиканың Күпфункцияле үзәгенә тапшырырга мөмкин. Шулай итеп, әлеге система ярдәмендә теләсә кайсы сайлау участогында тавыш бирергә була. Моннан тыш гаризалар Дәүләт хезмәтләре порталы аша, шулай ук территориаль сайлау комиссияләрендә кабул ителә. Аларны 11 мартка кадәр тапшырырга мөмкин.
- Россия Үзәк сайлау комиссиясе Владимир Путинны ил Президенты вазыйфасына кандидат буларак теркәде. Моңа кадәр комиссия партияләрдән кандидат булып барган өч кешене теркәгән иде инде. Болар – Леонид Слуцкий (ЛДПР), Владислав Даванков («Новые люди»), Николай Харитонов (КПРФ).

Искәртеп үтик: Президент сайлау өч көн – 15–17 мартта узачак. Татарстанда 2928633 кеше сайлау хокукына ия.

КАРАШ ҮЗГӘРДЕМЕ?

Мәгариф

«Укытучы елы үтте, гасыры башланды». Укытучылар һәм остазлар елының ябылу тантанасында Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин әнә шулай диде. Аның әйтүенчә, мөгаллимнәргә караш алга таба да кимемәячәк. Чарада катнашкан Рөстәм Миңнеханов республикада укытучы һөнәренең абруе зур булуын билгеләп узды.

Илдел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университетында узган тантанада бүләкләрне мулдан бирделәр. Рөстәм Миңнеханов мәгариф тармагының иң яхшы хезмәткәрләренә дәүләт бүләкләре тапшырды. Әйтик, Арча педучилищесының элеккеге директоры, хезмәт ветераны Илдус Сәгъдиевкә «Дуслык» ордены, Казандагы 6 нчы гимназия директоры Ольга Баклашовага «Фидакарь хезмәт өчен» медале бирелде. Алар арасында тәҗрибәле укытучылар, тәрбиячеләр, җитәкчеләр дә бар.

Башта Рөстәм Миңнеханов булачак педагоглар белән аралашты. Алар ничек итеп укытучы һөнәрен сайлавы турында сөйләде. Тантананы ачып: «Бу ел укытучы һөнәренең җәмгыятьтә дәрәҗәсе югары булуын күрсәтте. Ел дәвамында узган чараларда 65 меңнән артык педагог катнашты. Укытучының хезмәте җиңел түгел. Киләчәк сездән тора. Без сезнең белән горурланабыз», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Рәис әйтүенчә, яшь укытучылар өчен «Безнең яңа укытучы» гранты яңартылган. Укытучылар хөрмәтенә Казансу елгасы яр буенда сквер төзү һәм һәйкәл ясау эше башланган. Аны җәй көне ачарга җыеналар. Казан федераль университетында мәгариф музее булдырылачак. 36 меңгә якын укытучыга яңа ноутбуклар бирелгән. Техникум, көллиятләрдәге мөгаллимнәргә бирү мәсьәләсе дә хәл ителәчәк.

Рөстәм Миңнеханов республика мәгариф системасының илдә алдынгылардан булуын да әйтте. 2023 елда «Мәгариф» илкүләм проектындагы 15 чара тормышка ашырылган. Акчалар төзелешкә, мәктәпләрнең матди базасын яңартуга, педагогларыбызга ярдәм

итүгә тотылган. Алга таба да бу юнәлешләрдә эш дәвам иттереләчәк.

Татарстан «Яшь профессионаллар» бөтенроссия чемпионат хәрәкәтендә – 2, Бөтенроссия мәктәп укучыларының фән олимпиадалары нәтиҗәләре буенча 3 нче урында тора. Укытучылар хезмәте зур: 250 укучы Бөтенроссия олимпиадаларында җиңгән, призер булган. Өчесе химия һәм информатика буенча халыкара олимпиадаларда җиңгән. 2 меңнән укучы укудагы уңышлары өчен алтын медаль алган. 199 укучы БДИда – 100 балл, 9ы икешәр фәннән ике йөз балл туплаган.

Илсур Һадиуллин белдергәнчә, елның максаты – мәгариф хезмәткәрләренә булган мөнәсәбәтне үзгәртү, укытучының тоткан урынын билгеләү.

– Без моңа ирешә башладык. Укытучы елы бер елда гына тәгәлләнмичә, гасыр буе дәвам итәргә тиеш. Укучы укытучысын үзенең әти-әнисен яраткан кебек яратсын, хөрмәт итсен иде, – ди министр.

Илсур Һадиуллин районнарда яшь укытучыларга караш үзгәрүен тойган. Кемдер акча белән ярдәм итсә, кемдер фатир өчен түли. Бу – укытучыга булган карашны үзгәртү дигән сүз.

Министр журналистларга Укытучылар елында башланган проектлар турында да сөйләде. Март ахырында мәгариф тарихына багышланган китап бастырылачак. Бу тарихта беренче тапкыр. Матди як турында борчылу да бар. Казанда 70 укытучыга фатир бирелгән. Быел тагын 150сен түбәле итмәкчеләр.

«Ел укытучысы» бөтенроссия конкурсында призер булган Иннополис лицееның математика укытучысы Арман Костанян да теләкләрен җиткерде. Бүген мәктәпләрдә эшләү өчен барлык мөмкинлекләр тудырылуна басым ясады ул. Ә чара турында: «Ябылу түгел, бу әле мәгариф өлкәсендә нинди зур эшнең башы гына», – диде, зур өметләр баглап.

Азнакай районындагы 4 нче лицей директоры Илмир Шәйдуллиннан да мәктәп тормышы турында сорашырбыз. Аның әйтүенчә, әти-әниләр белән эшләү авыррак. Әмма укучыларның укытучыга хөрмәте арта бара. Моны ул мәктәпләрендә патриотик тәрбиягә игътибар артудан күрә.

– Гимн яңгырый, әлемнәр күтәрелә. «Мөһим сөйләшү» дәресләре үтә. Линейкада уңышка ирешкән укытучы, укучыларны бүләклибез. Укучылар барысын да күреп тора бит, – ди ул. – Чыгарылыш укучылары укытучыларның әйләренә хәл белешергә бара. Әгәр укучы урамда укытучысы белән исәнләшә белсә, укытучы үз бурычын үтәгән. Мин укучыларыма: «Безнең өчен шуннан да кадерлесе юк», – дип аңлатам. Еллар үтсә дә, белем биргән остазыңа карата хөрмәт кимергә тиеш түгел.

Сәрия МИФТАХОВА

kzn.ru

КАРЛЫ СЫНАУ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Мәсьәләгә әлеге йорт караган Торак милекчеләре ширкәте җитәкчесе Ләлә Хөсәенова ачыклык кертте:

– Ишегалдында кар җыеп барырга урын калмады. Аны чыгарырга кирәк. Ничәмә-ничә транспорт оешмасы белән сөйләштек, берсе дә килми. Кар эретү станцияләрендә чират, икешәр сәгать вакытны бушка әрәм итеп утырабыз, диләр. Аларга көндез эшләү отышсыз. Төнгә дә сөйләшеп карадык. Ике төн рәттән машина килде, тик ишегалдына керә дә алмыйча кире борылып киттеләр. Төнлә безгә үтә торган юл тирәсе машина белән тула. Бу – безнең ишегалдында яшәүчеләр генә дә түгел. Ул машиналарны нишләтергә? Бүген төнгә тагын сөйләштек, керә алырлармы, юкмы – билгесез. Узган атнада чүп түгү машинасы ишегалдына кереп батты да: «Юлларыгызны чистартып бетергәнче килмибез», – диделәр. Шуңа күрә хәзер чүп тә чыкмый. Менә шундый йомык бөҗра, – ди җитәкче.

Казанны кар тозагыннан коткарырга техника җитмәвен шәһәр мэры Илсур Метшин да инкарь итми.

– Узган атна буе буран нәтиҗәсе белән көрәштек. Башта әлеге афәтнең ни дәрәҗәдә зур булуын да чамалый алмадык, кар бертуктамыйча яуды. Соңрак исәпләдек: бистәләр һәм ишегалларын исәпкә алмыйча, беренче һәм икенче категориягә караган юлларда гына да бер миллион тоннадан артык кар яуган. Кайбер елларда кыш буена да 650 мең тонна чамасы кар чыгарган вакытлар бар, – диде ул. – Бөтен карны тиз генә җыештырып бетереп булмаячак. Өстәвенә шәһәргә авыр техника җитми. Без соңгы елларда күпләп сатып алган «Барсик»лар бу карлы буранда мәче балалары кебек кенә тоелды. Вазгыятьне бөтен республика буенча ишеп кар явуы, М7 һәм М12 трассаларын кар көртләреннән чистартуга шактый көч сарыф ителүе дә катлауландырды.

Аңлашыла ки, иң беренче чиратта зур юлларны кардан арындыралар, аннары – бистәләр һәм ишегаллары. Әле эш күп булса кирәк, шәһәрдә яңа эш атнасы кабат тугыз баллы «бөке»ләрдән башланды.

– Иң беренче чиратта, җәмәгать транспорты хәрәкәт итүче юлларны һәм социаль объектларга керү юлларын чистарттык. Кызганыч, барлык юлларны да тәртипкә китереп бетереп булмады әле. Мәсәлән, бер чакрым озынлыктагы ике полосалы юлны кардан чистарту өчен ике кар төяүче машина һәм авыр техника бертуктамыйча тәүлек буе диярлек эшләргә тиеш. Шәһәр күләмендә бу – меңләгән сәгать эш һәм меңләгән эшче дигән сүз, – ди башкаланың Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе башлыгы Альберт Салихов. – Кардан тиз һәм сыйфатлы итеп чистарту эшенә көндез – юлдагы хәрәкәт, ә төнлә юл читендәге машиналар комачау итә. Шуңа күрә алга таба аркылы урамнарны ябып торырга туры киләчәк. Шәһәр халкы моны аңлап кабул итсен иде.

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, юлны бездән башка беркем дә килеп чистартмаячак.

– Бу арада кардан чистарту – барлык шәһәр һәм район җитәкчеләре өчен дә төп мәсьәлә. Җәмәгать транспорты, ашыгыч ярдәм машиналары йөри алырга, чүп вакытында чыгарылырга тиеш. Сәүдә челтәрләрендәге азык-төлеккә дә игътибар итегез, – диде ул.

Башкаланың Салмачы бистәсендә яшәүчеләр ярдәм читтән килгәнне көтмичә, карны үзләре җыештырган.

– Без бистә читендә үк яшибез. Шуңа күрә башкаларга ышанырга, үзебезгә кымшанырга гына кала. Буранның өченче көнендә, өйдән чыгарга юл калмагач, 12 мең сумга трактор чакыртып (алар шуннан азракка килми дә), карны эттердек. Буран тынгач, 15 мең сумга зур техника яллап, аны читкә чыгардык. Соңрак тагын эттердек. Урам башында яшәүчеләр азрак, безнең ише еракта торучылар күбрәк түләде. Узган атнадагы буран миңа 3–4 мең сумга төште, – дип сөйләде Салмачы бистәсендә яшәүче Марат Җиһаншин.

Анысы да монысы, Казанда коммуналь хезмәтләргә ярдәм итәргә теләп, ишегалдына көрәк тотып чыгучыларны бүләкли башларга мөмкиннәр. Соңгы атнада күргәнебезчә, башкалада андый битараф булмаганнар да җитәрлек. Кайбер ишегалларында яшәүчеләр кышкы өмәгә кат-кат чыкты. Илсур Метшин андыйлардан, ишегалдын тәртиптә тоткан өчен, бер атнага түләү алмаска тәкъдим итте. Менә сиңа кар!

Эльвира ВӘЛИЕВА

Казанда кардан чистартмау турында кайда хәбәр итәргә?

Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары:
8 (843) 223-22-23

Вахитов һәм Идел буе районнары:
8 (843) 223-21-11

Киров һәм Мәскәү районнары:
8 (843) 223-29-99

Совет районы:
8 (843) 223-20-00, 8 (843) 295-77-05

«Иске шәһәр» префектурасы:
8 (843) 223-28-88

Казан мэриясе матбугат хезмәтеннән

Торак хәлләре

ТҮЛӘҮНЕҢ ДӘ ҖАЕ БАР

Быелның җәеннән Татарстанда яшәүчеләр коммуналь хезмәтләр өчен күбрәк түли башлаячак. Тарифлар халыкның күпчелеге өчен 10,8 проценттан да артмаячак, дип тынычландырдылар Татарстан Тарифлар буенча дәүләт комитетының еллык коллегия утырышында. Тик менә чимал белән тәэмин итүчеләр мондый бәяләр аркасында «яшәү өчен көрәш»тән зарланды. Ә ут һәм су өчен исәп-хисап ясарга теләмәүчеләрне торактан мәхрүм итәргә тәкъдим иттеләр. Утырышниләр белән истә калды?

Дәүләт комитетында былтыргы «үзенчәлекле» елга йомгак ясап, бу елгы үзгәрешләр турында сөйләделәр. Чарада Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин да катнашты. Яңа тарифлар турында сөйләшүгә керешкәнче, Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе Александр Груничевның 2023 елны ни өчен «үзенчәлекле» дип атавына да ачыклык кертик. Билгеле булганча, тарифлар гадәттә елга бер тапкыр – җәй көне артса да, 2022 ел азагында, ил Хөкүмәте карары нигезендә, коммуналь хезмәтләргә бәяләр бер ел эчендә ике тапкыр артты. Шуңа күрә 2023 елның җәендә тарифлар үзгәрешсез калды. Бер ел ярымлык «тынлык»тан соң, бәяләр кабат бу елның 1 июлендә кыйммәтләнәчәк.

– Татарстанның күпчелек районнарында (республикада яшәүчеләрнең өчтән икесе диярлек. – **Ред.**) коммуналь хезмәтләр өчен бәяләр күп дигәндә – 10,8, ә республиканың аерым муниципаль берәмлекләрендә 15,7 процентка кадәр артачак. Мәсәлән, Кукмара халкы өчен әлеге күрсәткеч 11,9 процент тәшкил итәчәк, – диде Александр Груничев.

Нишләтәсең, шул ук су да, мәсәлән, бөтен Татарстан халкына бер торбадан килми шул. Шуңа күрә коммуналь хезмәтләргә тарифлар да аерыла. Моңа кадәр коммуналь хезмәтләргә бәяләр кыйммәтләнүгә багышланган киңәшмәләрнең берсендә Питрәч авыл җирлеге мисалында исәпләп тә күрсәттеләр: бу җәйдә биредә су – 7,9, пычрак суларны агызу – 9,5, ут – 8,8, җылылык – 14, газ – 11,2, каты көнкүреш калдыкларын чыгару исә 4 процентка артачак. Авыл җирлеге буенча тарифлар уртача 11,3 процентка кыйммәтләнәчәк дигән сүз.

2024 елның 1 июленнән ут өчен бер ставкалы тариф 41 тиенгә артачак һәм бер кВт/сәгате 5,09 сумга җитәчәк. Электр плитәләре белән җиһазландырылган шәһәр йортларында бер ставкалы тариф 52 тиенгә кыйммәтләнеп, бер кВт/сәгате 4,10 тиен тәшкил итәчәк. Авылда яшәүчеләр өчен ул 29 тиенгә үсеп, бер кВт/сәгате 3,57 сум булачак. Табигый газның бер куб метры бәясе хәзерге 6,78 сумнан 7,47 сумга җитәчәк. Зәңгәр ягулык 69 тиенгә артачак. Бәяләр кыйммәтләнсә дә, тормыш дәвам итә.

Чимал белән тәэмин итүчеләр дә балда-майда гына йөзми. Утырышта катнашкан «Таткоммунэнерго» республика җитештерү берләшмәсе генераль директоры Әсфән Галәвов әйтүенчә, оешмага быел 14,5 миллион сумга кадәр зыян яный. Тарифлар әз-мәз генә арту аркасында предприятие эшчәнлеге яшәү өчен көрәшкә әверелә, дигән фикер белдерде ул.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Әлмәт районы башлыгы Тимур Ногуманов исә коммуналь хезмәтләр өчен исәп-хисап ясарга теләмәүчеләргә каршы көрәш турында сөйләде. Андыйлар нефть каласында да шактый икән.

– Шәһәрнең Белоглазов урамындагы бер фатир хуҗасы моннан берничә ел элек үк АКШка күченеп киткән. Торак өчен бурычы 500 мең сумнан да күбрәк җыелган. Аның белән элемтәдә торабыз: фатир хуҗасы кайтырга җыенмый, торагын сатарга теләми, әҗәтен капламый, – дип сөйләде район башлыгы.

Әнә шундый чаралар күрелүгә дә карамастан, коммуналь хезмәтләр өчен бурычларын капларга теләмәүчеләрнең милкен суд аша тартып алып, аны кечкенәрәк мәйданлы торакка алмаштырырга тәкъдим итте ул.

Премьер-министр Алексей Песошин сүзләренә караганда, республика буенча коммуналь хезмәтләр өчен әҗәтнең гомуми күләме 9 миллиард сумга якын тәшкил итә. Тармакның «авырткан җирләре» турында сөйләвен дәвам иттереп, Татарстанда инженер челтәрләрнең торышы да «бик әйбәт түгел» икәнен әйтте. Тик соңгысын тарифларны күпме генә арттырып та, хәл итеп бетереп булмаячак. Моны утырыш барышында да кат-кат әйттеләр. Ишеткәннәрдер, дип телик.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Еллык йомгак

КҮЗ УҢЫНДА

Татарстан прокуратурасы узган елгы эшенә йомгак һәм агымдагысына бурычлар куйды. Баш прокурор Альберт Суяргулов һәм аның командасы нәрсәгә аерым игътибар бирәчәк соң?

➤ **Прокурорлар 650 млн сумнан артык хезмәт хакы буенча бурыч түләттергән.**

➤ **67 меңнән артык халык гозере хәл ителгән. Бу 2022 ел белән чагыштырганда 18 процентка күбрәк.**

Ришвәтчелеккә каршы көрәш, хезмәт, социаль хокукларны яклау, торак-коммуналь хуҗалык юнәлешендә закон үтәлешен контрольдә тоту. Суяргулов, әнә шул юнәлешләрдә эшебезне дәвам итәчәкбез, диде.

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та үгет-нәсыйхәтен бирде. Әйтүенчә, салымны вакытында түләү, коррупция, ТКХ сорауларына да, законсыз үзләштерелгән милек мәсьәләләренә дә игътибарны арттырасы. Беренчесе җәһәтеннән Рөстәм Миңнеханов:

– Намуссыз бизнес вәкилләре, төрле юллар кулланып, салым түләүдән качарга тырыша. Прокуратураның көчен исәпкә алып, салым түләүдән азат ителә торган бер көнлек фирмаларны теркәү эшенә юл куймаска кирәк, – диде.

Прокуратураның күз уңында торырга тиешле тагын бер мәсьәлә – кешеләрне авария хәлендәге торактан күчерү. Сүз уңаеннан республиканың 12 районында мондый торакны сүтү проблемасы әле дә хәл ителми. «Прокуратурага коммуналь инфраструктура объектларын тиешенчә тоту турындагы закон таләпләрен үтәүгә, концессия килешүләренә, закон бозуларны кисәтүгә аерым игътибар бирергә кирәк», – диде Рәис.

Ришвәтчелек димәктән. «Ришвәтчеләр хакимияткә тап төшерә, халыкка зыян сала, канәгатьсезлек уята. Шаккатырырдай мисаллар шактый. Бу җәһәттән тиешле чаралар күрелергә тиеш», – диде Рәис. Хәер, баш прокурор, вазыйфага билгеләнгәч тә, коррупция очракларына карата булган мөнәсәбәте катгый булачагын әйткән иде инде. Вакыт хөкеменә калдырыйк.

ЖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Гыйлем, тамаша һәм икмәк

ВЦИОМ, ягъни иҗтимагый фикерне өйрәнү буенча илкүләм үзәк үткәргән сораштыруларны артык объектив дип булмаса да, алар россияле кавемнең матди ягын гына түгел, хәл-әхвәлен, кәефен һәм кызыксынуларын да барлап бара. Кызыксынулар дигәндә, соңгы ике дистә елда аларның күбесе бөтенләй диярлек үзгәрешсез икән.

Гавамны бүген, мәсәлән, бизнес, аның юнәлешләре, ничек җиңелрәк итеп акча табу, байлык туплау, сәяхәтләр, җиңел автомобильләр паркы нык кызыксындыра. Матди булмаган кызыксынуларга килгәндә, халык эстрада артистларын, аларның репертуарын, гаилә хәлләрен, маҗараларын яхшы белә, алар турындагы гайбәтне дә рәхәтләнеп тарата. Тик менә фикер ияләре, галим-голәмә, төрле уйлап табучылар, төгәл фәннәрдә уңышка ирешкәннәр, исемле инженерлар дигәндә, кызыксыну бөтенләй дә юк. Соңгы сораштыруларда һәр йөз кешенең берсе генә дә билгеле конструктор, галим яисә инженер исемен атый алмаган.

Ни өчен шулай соң? Ник халык атаклы физик, һәркемнең кесәсендәге телефонда кулланыш тапкан гетероструктуралар авторы, Нобель премиясе лауреаты Жорес Алферовны, Пуанкаре теоремасын исбатлаган затлы математик Перельманны, башкаларны белми, хәтта белергә теләми? Совет чорында без Гагаринны гына түгел, аны галәмгә очырган Королевны да, корал конструкторы Калашниковны, атомны иярләгән Курчатовны да белә, алар белән горурлана идек. Бүген халык Бузованы карап рәхәтләнә, аның турында сөйли, Басковны тикшерә, Киркоровны әллә кемгә чыгара, Ренат Рәхмәтуллинны «чәйни». Ягъни гавам, совет чорындагы белем һәм романтизм «чир»еннән бөтенләй үк «терелеп», фани дөньяда яшәүне яңадан күңел ачу, мал җыю, тәмле ашау аша кабул итә башлаган, борынгыдан, антик чордан калган «икмәк һәм тамаша» принцибы кабат өскә калкып чыкты.

Җилбәзәк гавам үзеннән дә җилбәзәгрәк һәм надан артистлар тормышын тикшереп яши икән, бу хәлне гавамга диагноз димичә ничек атарга? Бу – халыкның сыйфаты, дөресрәге, аның сыйфатсызлыгы. Һәм мондый күренеш без яшәгән илдә күзгә ныграк бәрелә, дисәк, ялгышмабыз. Кеше затын мөмкин кадәр киңрәк белемле, фикерле итәргә тырышкан белем системасы дөньяви тенденция булудан ерак торган мәлдә дә. Милләттәшебез, РАН академигы, АКШта да эшләп алган Роберт Нигъмәтуллин, ул илдә дә укучыларның 80–90 процентына белемне, гадиләштереп әйткәндә, синус-косинусларсыз, озын иншаларсыз, астрономиясез генә бирүләрен әйтә. Тик анда сәләтле бала-чаганы сайлап алу, үзләренең данлыклы университетларына димләү практикасы көйләнгән. Россиядә андый механизм юк. Бездә, киресенчә, 80–90 процент бернинди фильтрсыз вузга барып керә. Белем алудан да бигрәк, дипломлы булу өчен. Һәм дә... дипломда күрсәтелгән белгечлек буенча эшләмәс өчен. Кеше үз белгечлеге буенча эшләми икән, аның белеме юк дигән сүз. Аның нәтиҗәсе дә күз алдында – технологик арттalык, чималчылык.

Ә бит тангенс-котангенсларны инженерлар, математиклар да көн саен, атна саен кулланып тормый. Алар башлыча – башны эшләтү, мидәге сырларны, нейрон бәйләнешләрен арттыру чарасы. Сырлар күбрәк булган саен, бәндә гыйлемгә ныграк тартыла, аңа күп нәрсә кызык була башлый. Гыйлемлеләр күбәйгән саен, җәмгыять, дөнья яхшыра, затлылана. Аерым ил, аның алгарышы, үсеше турында әйткән дә юк. Нәкъ шуңа күрә дәүләт, куллaнучы, мал җыючылар, тәмле ашап, күңел ачып яшәүчеләр армиясен тулыландырмыйча, шәхесләр, аңлы һәм җаваплы затлар тәрбияләүне кыйбла итәргә тиеш тә...

Гыйлемсезлек, сансызлык Россияне бүген кадрлар кытлыгына да илтеп җиткерде. Бигрәк тә җитештерүдә. Вуз бетергәне дә, бетермәгәне дә, пицца ташыса ташый, белгечлеге туры килгән очракта да заводка бармый. Станок артына басар кеше юк. Вуз дипломы булганнар – гомумән дә «мулла». «Атка печән салучы гына» юк. Кадрлар кытлыгына төп сәбәпче – белем системасының без сөйләгән гариплеге, кайберәүләр әйтмешли, җимерелгән булуы. Махсус урта белем системасының агониясе. Дипломдагы белгечлек буенча эшләмәү дигәндә дәүләт ник пассив күзәтче ролендә соң һаман? Бу бит – болай да алга бармаган халык хуҗалыгын тагын да артка сөйрәү. Тупас әйткәндә, кешене биш ел буе чүлмәк ясарга өйрәтәләр. Ул укып чыга да чәч кисүче булып урнаша. Нигә ул чагында ул чүлмәкчелеккә укыган? Димәк, чүлмәкчеләр институтына конкурс түбән яисә акчаны азрак түлисе булган. Эш бирүчене дә хәзер аңламассың. Алар да белемнән бигрәк дипломга, аның барлыгы-юклыгына карый: «Кайдадыр нәрсәгәдер укыган, кеше барыбер кирәк, әйдә эшләп карасын инде». Нәтиҗәдә бездә федераль министрлар да үз белгечлеге буенча эшләми. Авыл хуҗалыгы министры Патрушев – элекке банкир, сәнәгать министры Мантуров – социолог һ.б.

Социологны, банк эше белгечен, икътисадчы, менеджер, юристны әзерләү җиңелрәк. Ул юнәлешләр буенча уку да җиңел. Катлаулы сызымнар сызасы, четерекле технологияләр белән баш катырасы юк. Әмма баш катырырга барыбер туры киләчәк. Белем системасы, кадрлар дигәндә, агым уңаена йөзүдән туктап, кулга ишкәкләрне иртәме-соңмы аласы булачак. Никадәр иртәрәк алсак, шулкадәр яхшы...

Адәми затның җиһандагы билгеләнеше «күсе узышы»нда катнашу, кеше көнләшерлек итеп күңел ачу, дөньяның артына тибеп яшәүдә түгел. Тормыш мәгънәсе – зурдан алганда, яшәешне, дөньяны аңларга тырышу, аңлау, аны мөмкин кадәр камилрәк итүдә катнашу, дисәм, Америка ачмам. Әлбәттә, гыйлем аша. «Дәүләтнең белем бирү системасы да шул максатка юнәлергә, бәндәгә шуны аңлатырга, тукып торырга тиеш түгелме?» – дип сорыйсы килә. Алда әйтелгән билгеләнешне һәр ун кешенең берсе генә аңлаган, кабул иткән очракта да без гел башка, күпкә камилрәк илдә, дөньяда яшәр идек бит...

ФОАТ ӘХМӘТҖАНОВ:

«ЯМАН ЧИР – БЕТТЕҢ ДИГӘН СҮЗ ТҮГЕЛ»

Шәхес

Табиб җылы сүз белән дә дәвалый. Тапталган кебек тоелса да, бу фикернең актуальлегенә, мөгаен, беркем дә шикләнмәс. Медицинаның иң четерекле тармагында – онкологиядә бу бигрәк тә мөһим. Кешене өмет яшәтә, дип юкка гына әйтмиләр бит. Бу көннәрдә тугызынчы дистәне вакларга җыенган, бөтен эшчәнлеген шушы өлкәгә багышлаган, меңнәрчә кешегә гомер бүләк иткән Фоат ӘХМӘТҖАНОВ әлеге сүзләр белән тулысынча килешә. Ул үзе дә шундый халәттә яши, эшли: бертуктаусыз телефон шалтырый, ишек төбендә халык чиратта утыра, шәкертләре киңәш-табышка керә...

:: Фоат абый, яшерен-батырын түгел, элек-электән яман чир ачыкланган яки шикләнгән кеше ничек тә булса сезнең белән күрешергә җай эзли. Мондый болгавыр заманда һәр кешенең күңелен күрергә ничек өлгерәсез?

– Пациентлар белән әңгәмә корып утыру өмет уяту, җылы мөнәсәбәтләр урнаштыру өчен генә түгел әле ул. Сүз дә юк, анысы да бик кирәк. Әгәр тәфсилләп сөйләшеп утырмасаң, күп нәрсәне белеп бетермәскә мөмкинсең һәм, диагноз куйганда ялгышлык китеп, дәвалауның да дөрес булмаган юлга кереп китүе бар. Кайчак авыруны ачыклау өчен кечкенә генә берәр факт та ярап куя. Бигрәк тә олы яшьтәгеләр үз халәтен әллә ни аңлатып бирә алмыйлар, шуңа күрә аларның бер генә сүзен дә игътибарсыз калдырмаска, өстәмә сораулар бирергә кирәк. Кайберәүләр хәтта кайчан авырый башлаганын да төгәл генә әйтә алмыйлар.

:: Югыйсә яман чирне вакытында ачыклау кешенең гомерен озынайтырга ярдәм итәр иде...

– Һичшиксез. Әгәр пациент: «Бер ел тирәсе авырып йөрим инде», – дип әйтсә, чир шактый таралган була инде. Чөнки шеш яңа үсә башлаган чагында бернинди билгеләр дә булмый әле. Элек шешләрне бик тиз үсә дип уйлыйлар иде. Тикшерүләр күрсәткәнчә, алай булып чыкмады. Дөрес, төрлесе була. Иң тиз үсә дип саналганнарыннан, мәсәлән, үпкәдә, күкрәк бизендә шеш ике ел буена бер куб сантиметрга кадәр үсәргә мөмкин. Аннан үсеш яшен тизлегендә була: бер ел эчендә ул сигез тапкыр арта. Әгәр шеш аз гына булса да үскән икән, димәк, шикләнергә нигез бар. Ә инде дәваланганнан соң, табибка вакытында күренеп, кирәкле тикшеренүләрне узып торганда, организмда өч ел үзгәреш булмаса, авыру башка кабатланмас дип, 95 процент очракта ышанырга була. Бу – кеше дәваланып бетте дигән сүз. Әмма чир бик мәкерле, калган 5 процент очракта ул башка урыннарда килеп чыгарга мөмкин. Кайбер очракларда бүтән органнарда яңа төр шешләр килеп чыккалый. Шуңа күрә, дәваланып беткән кебек булсаң да, уяулыкны югалтмаска, кирәкле тикшеренүләрне үтеп торырга кирәк. Моның өчен күп кенә дәвалау оешмаларында «башлангыч онкологик кабинет»лар (ПОК) оештырылган. Шушы хастаханәләрдә бер ел ярымда – өч ай саен, аннары өч елга кадәр – ярты ел саен, өч елдан соң ел саен тикшеренеп тору зарур.

:: Организмда яман шеш барлыгы икешәр ел буена берничек тә сизелмәскә мөмкин, дисез. Ә ничек ачыкларга?

– Әйе. Хәтта бик нык таралган вакытта да бернидән шикләнмәгән авырулар бар. Безнең илдә хәзер җирле поликлиникаларда диспансерлаштыру һәм скрининг дигән тикшеренү эшләре кертелгән. Алар – икесе ике нәрсә. Профилактик карау вакытында күз алдында тотылган органнар тикшерелә, скрининг исә биш органны онкологик авырулар буенча тикшерүне күздә тота.

Әлбәттә, тикшеренеп йөрү җиңел түгел. Элегрәк: «Нәрсә чир эзләп йөрисең инде?» – дип ризасызлык күрсәтүче табиблар да очраштыргалый иде. Хәзер андый очраклар юк дип беләм. Икенче яктан караганда, өч ай түгел, ел саен тикшеренү өчен дә табибларны каян аласың? Юк бит алар. Димәк, тикшеренү эшләре күп урында буш куыкка әйләнергә мөмкин. Шулай да иң төп сәбәп – халыкның чакырган вакытта табибка күренмәве. Форсаттан файдаланып, газета укучыларны тагын бер кат кисәтәсем килә.

> Тикшеренергә чакырганнар икән, бармый калмагыз. Бу – яман чирне вакытында ачыклауның бердәнбер чарасы.

:: Татарстанда онкология чиренә каршы көрәш йөзеннән шактый зур эшләр эшләнде бит. Һәрхәлдә, Кремль астында хәлләр бик мөшкел кебек иде.

– Эшләнде һәм эшләнә. Әмма җитәрлек түгел. Бүген безнең хастаханәдә 840 урын бар, тагын 500 урын – «дневной» стационарда. Әмма тагын шулкадәр булса да, чакка гына туры килер иде әле. Урын җитмәү сәбәпле, авырып киткән кеше белән әзерлек эшләре дә алып бара алмыйбыз.

Иң кызыгы шунда: иминиятләштерү оешмасы күпме кешене дәваларга кирәклеге турында план бирә. Үзләре, яман чир белән авыручылар онкология учреждениеләрендә дәваланырга тиеш, диләр. Чөнки, чыннан да, мондый чирне хәзер химия һәм нур терапиясеннән башка дәваламыйлар. Шулай булгач, нинди план турында сүз барырга мөмкин? Җитмәсә, бездә тиешле дәрәҗәдә җиһазланган тернәкләндерү үзәкләре дә юк. Ә алар бик кирәк.

:: Хәтерлим әле, элегрәк яман чир белән авырып киткән кеше үзе дә белми, бәлки белмәмешкә сабышкандыр, туганнары да диагнозын яшерергә тырыша иде. Хәзер инде эш яшерүдән узды кебек. Шулай да авыруга баштан ук диагнозны турыдан-туры әйтү бик зур стресска китерәдер, мөгаен. Кирәкме икән ул?

– Элек ул, чыннан да, әйтелми иде. Монда төп рольне табиблар этикасы дигән нәрсә уйнады. Үзгәреш елларыннан соң бу хәл ничектер үз агымына куелды. Хәзер инде заманасы да, чире дә бүтән дигәндәй, авыру кеше үзе дә сизенә, белә торгандыр дип уйлыйм. Әмма аның бу сүзләрне ишетәсе килми. Шуңа күрә мин үзем күп сөйләнеп йөрү ягында түгел. Минемчә, табиб кирәк нәрсәне авыруга итагатьле генә аңлатырга тиеш. Әлбәттә инде, алдан туганнары белән сөйләшеп алу бик мөһим.

Сан

Бүген Татарстанда **15 меңгә** якын, Россиядә **3 млн 970 меңнән** артык кеше онкологик авырулар буенча исәптә тора. Бу – барлык халыкның **3 проценты** дигән сүз. Алар арасында беренче стадиядә – **30**, икенче стадиядә – **25–30 проценты**, калганнары – 3 һәм 4 нче стадиядә.

:: Белүемчә, яман чир төрләренең килеп чыгу сәбәбе әле һаман да җавапсыз кала. Шулай да, кызыксына башласаң, сакланырга кирәк әйберләр – тулы бер исемлек. Мөһимрәк дигәннәрен искә төшереп үтик әле.

– Гайре табигый нәрсәләр юк. Бары тик яшәү рәвешен нормада тотарга гына кирәк. Беренче чиратта ашау-эчүне көйләргә, артыгын ашамаска, чөнки бу бавыр авыруларына китерә һәм иммунитетны бетерә. Тәмәке тарту, гомумән, 50 процент очракта теге яки бу чирнең сәбәпчесе булып тора, ә инде рак авыруларына килгәндә, әлеге сан – 30 процент тирәсе. Аракы эчүчеләрнең бавырлары бик тиз сафтан чыга. Күбесе цирроздан үлеп китә. Исән калган очракта исә бу яман чиргә туры юл булыр иде. Аннан килеп, организмны гел тикшереп, теләсә нинди ялкынсынган урыннарны юк итәргә кирәк.

:: Зур акча түгеп, кредитлар рәсмиләштереп, күпләр ни өчен чит илдә дәваланырга тели?

– Анда әйбәт дип уйлыйлар. Чынлыкта, чит илләрдән кайтып егылган пациентларны безгә бик күп дәваларга туры килде. Шунда үлеп калучылар да бар. Әйтергә кирәк, соңгы вакытларда мондый караш үзгәрә башлады инде...

:: Фоат абый, әңгәмә башында ук сез, гомеремне онкология өлкәсенә багышладым, дигән идегез...

– Укуны тәмамлагач та, туган ягымда өч ел эшләдем әле. Анда кайтуга хирургия бүлеге мөдире итеп куйдылар. Баш табиб вазыйфаларын да үтәп алдым. Казанга килергә уйладым да, шәһәр онкология диспансерына юл тоттым. Бик әйбәт каршы алдылар, хирург итеп тәгаенләделәр. Шушы еллар эчендә ясаган операцияләремнең исәбе-саны юк. Хәзер дә атнага 5–6ны ясыйм әле. Исәбе юк, дисәм дә, һәрберсе башка кереп кала, күз алдымда тора, һәрберсенең нәтиҗәсен теләсә кайсы вакытта әйтеп бирә алам. Бу, икенче төрле әйткәндә, тәҗрибә дигән сүз инде. Дәвалау буенча яңадан-яңа методикалар уйлап табабыз, аларны акрынлап тормышка ашырабыз. 13 патентым бар, бүген алар барысы да кулланылышта.

– Өч кызыгызның да онколог булып китүе – искиткеч күренеш инде ул. Димәк, гаиләдә әти кеше буларак та, һөнәр иясе буларак та абруегыз бик зур булган?

– Бәлки. Әмма кызларым һөнәрне дә, бу юнәлешне дә үзләре сайладылар. Укытучы әниләре генә: «Анда бармагыз, бик авыр эш ул», – дип әйтә килгән иде. Тыңламадылар. Үкенгәннәрен ишеткәнем юк. Ә авыр дигәннән, чыннан да, көне-төне эш урынында булырга туры килде бит. Көндез – авырулар, кичен – диссертацияләр, патентлар... Кызларым да кирәк чакта төнгә кадәр эшлиләр.

– Юбилеегыз белән котларга килгәч тә, гел эш турында сөйләшергә туры килде бит әле.

– Зыян юк. Бу – минем яшәү рәвешем. Тормышымдагы көенечләрем дә, сөенечләрем дә, уйлануларым да, эзләнүләрем дә – барысы да шуңа бәйле.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ӘҢГӘМӘНЕҢ ТУЛЫ ВАРИАНТЫ САЙТТА

КОТЛЫЙБЫЗ!

«Алабуга бөке һәм пластмасса эшләнмәләр ясау предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте коллективына, «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Спас муниципаль районындагы республика матди ярдәм үзәгенең 38 номерлы бүлекчәсенең социаль эш буенча белгече **Гомәрова** Наталья Владимировнага, «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Питрәч муниципаль районындагы «Кайгырту» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең өйдә хезмәт күрсәтү бүлекчәсе социаль хезмәткәре **Хисаметдинова** Роза Шәйхулла кызына, Татарстан Республикасы прокуратура органнары ветераны **Абдулкасыймов** Марат Шамил улына, Татарстан Республикасы прокуратурасының оборона-сәнәгать комплексы өлкәсендә законнарның үтәлешенә күзәтчелек бүлеге прокуроры **Власова** Елена Юрьевнага, Татарстан Республикасы прокуратура органнары ветераны **Гринь** Петр Михайловичка, Татарстан Республикасы прокуратура органнары ветераны **Дмитриев** Михаил Александровичка, Татарстан Республикасы прокурорының оештыру мәсьәләләре һәм үтәлешне контрольдә тоту буенча ярдәмчесе **Ковалюк** Максим Александровичка, Татарстан Республикасы прокуратура органнары ветераны **Лотфуллин** Әнвәр Миңнулла улына, Татарстан Республикасы прокуратура органнары ветераны **Миргалимов** Раиф Мирхаҗиян улына, Татарстан Республикасы прокуратура органнары ветераны **Нуриева** Гөлсинә Гарәфетдин кызына, Татарстан Республикасы прокуратура органнары ветераны **Сурулев** Юрий Александровичка, Татарстан Республикасы прокуратурасының тикшерү, башлангыч тикшерү алып баруга һәм оператив-эзләү эшчәнлегенә күзәтчелек идарәсе башлангыч тикшерү алып баруга һәм оператив-эзләү эшчәнлегенә күзәтчелек бүлеге өлкән прокуроры **Шакиров** Руслан Равил улына, Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының хокукый һәм кадрлар белән тәэмин итү бүлеге башлыгы **Фугин** Владимир Валерьевичка, Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының инвестицияләр җәлеп итү эшчәнлеген координацияләү бүлеге башлыгы **Чернова** Марина Иннокентьевнага, «Халыкара программалар дирекциясе» автоном коммерциячел булмаган оешмасы генераль директоры вазыйфаларын башкаручы **Шәйхетдинова** Диана Олеговнага, **«Нуриевлар клиникасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте коллективына**, Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Идел-Кама төбәкара идарәсе хезмәткәрләре: дәүләт экология экспертизасы һәм рөхсәт кәгазьләре бирү эшчәнлеге төбәкара бүлеге баш белгече-эксперты **Әгъләмҗанова** Алия Айдар кызына, түләүләрне контрольдә тоту төбәкара бүлеге башлыгы **Мостафина** Лиана Наил кызына, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы хезмәткәрләре: җир ресурслары идарәсенең җир мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлекне оештыру бүлеге әйдәүче консультанты **Латышева** Екатерина Семеновнага, җыелма-аналитика бүлеге башлыгы **Проценко** Дарья Ивановнага, корпоратив идарә бүлеге башлыгы **Тюрикова** Вероника Александровнага, **«Альянс» идарәче компаниясе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте коллективына**, **«Ромекс-Кубань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте коллективына**, **«Мәгълүмат проектларына идарә» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте коллективына**, **«Татарстан Республикасының Мәгълүмат технологияләре үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе коллективына Татарстан Республикасы Рәисенең Рәхмәте** белдерелде.

***

Республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Битаман» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (Татарстан Республикасының Биектау районы) **Вахитов** Шәүкәт Җәүдәт улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

Мәгариф өлкәсендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәренең «1 номерлы кичке (сменалы) гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреж дениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Алиева** Альбина Әдип кызы, «Казан медицина көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе укытучысы **Субаева** Миңнегөл Шәмсулла кызы; эчке эшләр органнарында күпьеллык намуслы хезмәте, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы ветераны, отставкадагы эчке хезмәт подполковнигы **Сәхапов** Рафаэль Закир улы; республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Апас муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы **Гыйсмәтов** Радик Ринат улы, «КӨНЧЫГЫШ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш агрономы (Татарстан Республикасының Кукмара районы) **Мөхәрләмов** Илфат Вакыйф улы; республикада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү системасын үстерүгә зур өлеш кертүләре, нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең Ютазы филиалы бүлеге башлыгы **Сәлимгәрәева** Ирина Васильевна, «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең Балык Бистәсе филиалы бүлеге башлыгы **Сафиуллин** Нурислам Васил улы, «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең административ бүлеге баш белгече **Сафонова** Виктория Михайловна; финанс-икътисад эшчәнлегендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Җәзаларны үтәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе 19 номерлы хезмәт белән төзәтү колониясе» федераль казна учреждениесе бухгалтериясе бухгалтеры **Сафина** Зинаида Мөхәммәтхан кызы; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм республикада юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүгә зур өлеш кертүе өчен «Идел буе» тәҗрибә лабораториясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Ярмиев** Марат Фәрит улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

«Россия авыл хуҗалыгы үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалы Актаныш район бүлеге агрономы **Мостаева** Илүзә Мәхтүм кызына **«Татарстан Республикасының атказанган агрономы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Татарстан» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең терлекләр караучы эшчесе (Татарстан Республикасының Биектау районы) **Зиннәтуллина** Илсөя Газизулла кызына, «Сөләйманов Әхтәм Исмәгыйль улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы терлекчесе (Татарстан Республикасының Нурлат районы) **Исхакова** Халидә Йосыф кызына, «Чишмә» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең машина белән сыер саву операторы (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Сәлимгәрәев** Илгизәр Хәмит улына **«Татарстан Республикасының атказанган терлекчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Нурлат Мелиоводстрой» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Галимҗанов** Фәнис Зөлкарнай улына **«Татарстан Республикасының атказанган мелиораторы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Чынлы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тракторчы-механизаторы (Татарстан Республикасының Чүпрәле районы) **Вәлиев** Фәнис Фатыйх улына, «Агромастер» җитештерү компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең цех башлыгы (Татарстан Республикасының Мөслим районы) **Мөхәмәтов** Рифгать Хәертдин улына, «Август-Мөслим» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Минзәлә» аерымланган структур бүлекчәсе механика остаханәсе мөдире **Хәлиуллин** Рәмзил Фәрит улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«ЧАЛЛЫ ИКМӘГЕ» акционер җәмгыятенең кондитерлык цехы башлыгы **Гобәйдуллина** Люция Мәгъсүм кызына, «Азбука сыра» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Мамадыш заводы» филиалы 2 номерлы корпусы башлыгы **Сәхәбетдинова** Илзирә Амур кызына, «Казан сөт комбинаты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җитештерүне техник тәэмин итү хезмәте азык-төлек продукциясе җитештерүендә линия операторы **Чукуров** Николай Александровичка, «Татспиртпром» акционер җәмгыятенең «Мамадыш спирт заводы» филиалы баш инженеры **Шахаев** Алексей Александровичка **«Татарстан Республикасының атказанган азык-төлек сәнәгате хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

ЯҢА САЛА ТӨСЛӘРЕ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Авыл капкасы

«Безнең авылда бер әйберне дә читтән кеше чакыртып ясатмыйлар». Балык Бистәсе районының Яңа Сала авылында яшәүчеләр әнә шулай ди. Ни өчен дигәндә, һөнәрчеләре – үзендә. Кемдер тәрәзә йөзлеге, өйгә кирәкле җиһазлар ясый, кемдер оекбаш, шәл бәйли. Арада 93 яшьлек чабата үрүче Нәгыймулла бабай Хәбибуллин да бар. Авылның ничек көн күрүен үзебез күреп кайттык.

Яңа Сала артык зур авыл түгел. Анда 96 хуҗалыкта 225 кеше яши. Авыл кешесе терлек асрый, һөнәрчелек белән шөгыльләнә. Кешеләре исә үз тарихын да яхшы белә. Без моннан 7 ел элек шәһәрдән туган авылына күченеп кайткан тарих фәннәре кандидаты, тарихчы Нурулла Гарифны да очраттык. Үзе яшәгән йорт янында төбәкне өйрәнү тарихы музее төзегән икән.

– Безнең авыл үзе бер дәүләт кебек. Нинди генә һөнәр ияләре юк. Телефоннан гына заказ биреп, йорт та төзеп була. Тимер капка кирәкме, өстәл-урындыкмы – авыл егетләре хәзер эшләп бирә. Төзелеш материалы ясаучылар да бар. Кызларыбыз кул эшен булдыра. Авылдагы матурлык ул – авылдашларның үз куллары белән тудырган байлыгы. Әмма шундый иркенлек, матурлыкта яшәүчеләрнең аз булуына көенәм мин. Нишләптер кеше шәһәргә ябышып ята. Татар әбиләре оныкларын карашырга бара. Кайчак кешенең күңелен дә аңламыйм. Туып-үскән җире ул аның. Без беренче сыйныфта 33 бала укыдык. Шуларның күбесе кайтып та карамый. Авылда җан рәхәте бит, кайтсыннар иде, – ди ул.

Нурулла Гариф әйтүенчә, авылның тарихы Кама Тамагындагы Яңа Сала дигән авылга барып тоташа. Анда 11 тегермән булган, өчесе – су, сигезе – җил тегермәне. Хәзер зиратлары гына 11 гектар мәйданны били. Җир, утын җитмәгәч, 1845 елда шушы якка 11 гаилә күченеп килгән. Яңа Сала бердәм булуы белән аерылып тора. Авылдан чыккан кешеләр арасында мәчет, зиратны карап тотучылар, клубка булышучылар да бар. Бар җирдә тәртип. СанПиН белгечләре килгәндә, штраф салырга бер сәбәп таба алмый. Бу да – авыл үзенчәлеге. «Авыл өчен эшләмәсәң, ул сине белми. Ә Яңа Сала игелекле кешеләрен онытмый», – ди Нурулла Гариф.

Милли бизәкләр

Монда күз иң беренче авыл йортларындагы, капкалардагы милли бизәкләргә төшә. Ә аны ясаучы оста – 64 яшьлек Зиннур абый Гаянов.

– Бөтен эшләгән эшем милли бизәкләрдән тора. Ихтыяҗ бар. Үземдә генә дә 300дән артык бизәк бардыр. Урын җитмәгәч, остаханәмнең түшәменә кадәр ябыштырдым. Буш вакытта аларны карандаш белән кәгазьгә төшерәм. Уйлап чыгарганы да, интернеттан тапканы да бар, – ди ул.

Казандагы сәнгать училищесын тәмамлаган Зиннур абый. Аннан күршедәге Шомбыт мәктәбендә 11 ел рәсем дәресләре укыткан. Әтисе балта остасы булгач, кечкенә Зиннур барысын да күреп, эшләп үскән. Остаханәсенә дә җиһазларны кулдан ясаган. Кибетнеке кыйммәт бит. Капка, койма, беседка, чардуганнар, өстәл-урындыклар – ниләр генә ясамый. Сораучылар булганда, нигә кул кушырып ятарга? Тырышкач, табышы да бар.

Аның йорты матурлыгы белән аерылып торган. Тик янгын чыгып, барысы да әрәм булган. Хәзерге яңа йорты да игътибарны җәлеп итәрлек. Капкасында – лалә чәчәкләре. Өй кыегына ерактан күренеп торган бизәк ясамакчы.

Сер

Авылда әле кич утыру гадәте дә бетмәгән. Анда күршедәге хатын-кызлар җыелышып, җырлый-җырлый шәл, оек, бияләй бәйли.

Гүзәлия Шиһапованың шәле иясен көтеп ятмый. Кул эшен сатып тора. Кышка 4–5әр шәл бәйли. Моның өстенә, оекбаш-бияләен. Көндез өй

тирәсендә эш бетми. Кич утырган арада әле бу. Әлеге шөгыльгә 6 яшьтән үк өйрәнгән. 60 ел буе бәйләп, остарып беткән инде.

– Табышы әллә ни күп түгел, әмма ияләнгәч, ташлыйсы килми бит. Үзенә тартып тора. Бер кыенлыгы да юк. Ак, көлсу, кара төстәге шәлләр бәйлим. Кәҗә мамыгын сатып алам. Бер шәллек мамык – 1100–1200 сум. Мамыкны юам, аны кул белән эрлим, – ди Гүзәлия апа эш һәм аш турында.

Гүзәлия апа безгә яхшы шәл сайлау серен дә чиште. Җебе азрак, мамыгы күбрәк була икән. «Җебе бер кат булсын. Сатып алганда, шәл кырыннан булавка белән шуны карагыз. Аптырамагыз, баштарак кабармый, яба-яба матурая», – ди оста шәлче.

Чабатачы

Нәгыймулла абый Хәбибуллинга – 93 яшь. Бүген ул яраткан Гадиләсе белән улы, килене тәрбиясендә яши. Шушы яшькә кадәр чабата үргән әле ул. Артистлар да гел сорап торган. Аның чабаталары хәтта Америка, Германиягә кадәр үк киткән.

Армиядән кайткач, колхозда машина йөрткән, төзелештә эшләгән, мәктәп мичен яккан. Аның 13 миче булган. Утын дөрләгән арада чабата үрергә дә вакыт тапкан.

– Әни өйрәткән шөгыль бу. Юкә мунчаласын тота башлаганга 83 ел инде. Без алты бертуган идек. Хәзер икебез генә калдык. Гаиләдә әни, ике сеңлем һәм мин үрдем. Әни Чистайга алып барып сатып, шул акчага икмәк алып кайта иде. Авыл кешесе тамагын шул акчага туйдырды. Мәктәпкә чабата киеп йөрдек. Яз-көзен, кышын тиз туза иде ул. Астына күтәрмә куя идек, – ди тиктормас бабакай. – Башта авыл кешеләре шактый үрде. Аннан сораучы беткәч, үзем генә калдым. Мин тиз һәм җиренә җиткереп ясадым. Көнгә кайчак ике пар үргән чаклар да булды.

Сәрия МИФТАХОВА

САКЛАНА БЕЛҮ КИРӘК

Нәтиҗә

Терлекләр арасында очрый торган йогышлы авырулардан сакланырга, республикага куркынычсыз булган мал һәм ризык кына кертергә. Баш ветеринария идарәсе һәм Татарстан буенча Россельхознадзор идарәсе алдына куелган төп бурычлар әнә шулар.

Биологик саклаunion

Билгеле булганча, узган ел да ветеринарлар өчен сынаулы булды. Аларга кош гриппы, бруцеллез кебек йогышлы авырулар белән көрәшергә туры килде. Шуңа күрә, Баш ветеринария идарәсе башлыгы Алмаз Хисаметдинов коллегиядә әйтүенчә, алда хуҗалыкларны ябык режимга күчерү бурычы тора.

– 10, 15 ел элек аларны ябык режимга күчерү кирәкми иде. Соңгы елларда мөгезле эре терлекләр арасында авырулар артты. Моннан тыш, әллә кайчан онытылганнар да кире кайта. Елдан-ел куркыныч көчәя генә. Алга таба хайваннарны ачык режимда тоту мөмкин булмаячак. Бу бер көндә генә хәл ителә торган мәсьәлә түгел, әлбәттә. Тик терлекчелек комплекслары сакланырга тиеш, – диде җитәкче.

Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров та республикага йогышлы авырулар керү проблемасы һаман да актуаль булып калуын әйтте. – Баш ветеринария идарәсенә дә, Татарстан буенча Россельхознадзор идарәсенә дә терлекләр һәм кошлар арасында йогышлы авыруларны профилактикалауга зур игътибар бирергә кирәк. Бигрәк тә терлекчелек объектларының биологик сакланышын тәэмин итү сорала. Моннан оешмаларның иминлеге генә түгел, ә бөтен төбәкнең азык-төлек куркынычсызлыгы тора, – диде министр.

Исәпкә алу

Алмаз Хисаметдинов әйтүенчә, әлеге вакытта гомум секторда эре мөгезле терлекләрнең – 91, вак мөгезле терлекләрнең – 11, атларның – 14, дуңгызларның – 63, кошларның 28 проценты исәпкә алынган.

Әлеге эшләр быелның 1 сентябренә кадәр төгәлләнергә тиеш.

– Мәҗбүри идентификацияләү турындагы законны без күптәннән көттек. Республикада әзерлек эшләре 2020 елдан бирле барды, – диде ул.

Кабаннарны бетерергә

Билгеле булганча, узган ел республикада дуңгызларда Африка чумасы белән авырган очраклар ачыкланмады. Тик бу әле иркен суларга мөмкин дигәнне аңлатмый. Татарстан буенча Россельхознадзор идарәсе җитәкчесе Илнур Галиев әйтүенчә, республикада меңнән кимрәк булган дуңгыз тоткан ике хуҗалык тышкы факторлардан начар сакланган. Аларның икесе дә – Сарман районында.

Татарстанның Биоресурслар буенча дәүләт комитеты мәгълүматларына караганда, әлеге вакытта республикада 666 баш кабан бар. Аларның 400е – ана кабан. Узган ел 2,5 мең баш дуңгыз юк ителүгә карамастан, бер кабан елына 10 бала китерә дип исәпләсәк, кабан дуңгызларының саны 4 меңнән артык булачак.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Кабаннарның санын арттырмас өчен аларны тулысынча юк итәргә кирәк. Кабан яшәгән җирдә дуңгызчылык белән шөгыльләнеп булмый! – дип катгый кисәтте Илнур Галиев.

Кешеләр өчен куркыныч

Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе Марина Патяшина республиканың өч предприятиесендә санитар һәм ветеринар кагыйдәләр үтәлеп бетмәү нәтиҗәсендә унөч кешедә бруцеллез авыруы ачыкланганлыгын хәбәр итте.

– Шундый ук хокук бозулар терлекләрдә туберкулез авыруы ачыкланган тагын ике оешмада теркәлде. Туберкулезның микобактерияләре бруцелла кебек үк актив булмаганга күрә генә хезмәткәрләре авырмады, – диде ул.

Аның сүзләренчә, терлекләрдән кешегә күчә торган йөздән артык авыру барлыгы билгеле. Аларның алтысы аеруча куркыныч: кош гриппы, сальмонеллез, котыру авыруы, себер түләмәсе, бруцеллез һәм туберкулез.

Марина Патяшина әлеге авырулардан вакцинация эшләргә кирәклеген искә төшерде. Аеруча кош фабрикаларында, дуңгызчылык комплексларында эшләүчеләргә һәм зоопарк хезмәткәрләренә прививка ясатырга кирәк. Мондый коллективлар 75 процентка вакцинацияләнгән булырга тиеш.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Арабыздан беребез

Гади дә, гали дә

Кайбер кешене якыннанрак белгәч, тизрәк ерагаясы килә, кайберәүләр белән тагын да якынаясы, аларның күңел җылысында җылынасы, күңел байлыгына сокланасы килә.

Әңгәмәдәшем турында җырлар авторы буларак белә идем инде («Сорамагыз хәлләремне», «Балам-багалмам» һ.б.), ләкин үзем өчен аның күңел дөньясының никадәр тирәнлеген, холкының егетләрчә гаярьлеген «Васильево» санаториенда бергә ял иткәндә генә ачтым. Сүзем – Рәсимә Гарифуллина турында. «Ком сәгате»ндә чыгыш ясаганда дөрес әйтте ул: авыл җирендә яшәүче шагыйрьләр һәрвакыт күз уңында булмагач, бераз читтәрәк кала шул. Игътибардан да, бүләк-премияләрдән дә, нәшриятның хәерхаһлыгыннан да. Рәсимә апа турында моңа кадәр аз белүемнең сәбәбе дә бәлки шулдыр.

Гомер буе гаделлек өчен көрәшеп яшәгән кеше ул Рәсимә апа. Егерме биш ел район газетасында, унбиш ел халыкны эш белән тәэмин итү үзәгендә җитәкче буларак, шигырьләре-хикәяләре аша үз сүзен ишеттереп яшәгән, яши. Принципиальлеге, туры сүзлелеге аркасында «келәм»гә дә, суд каршына да басарга туры килә. Тик үзенең хаклыгына инанган кешене боларның берсе дә куркытмый. Сүзен курыкмыйча, өздереп әйтә ул.

Озак еллар иҗади тандем булып, фикердәш-дус булып яшәгән ире Кыяметдин вафат инде. Андый кеше башка юк ул, ди Рәсимә апа. Ул үзе дә – уникаль шәхес. Шигырьләрен көйләп язса, алар популяр җыр булып китә, поэмаларының төшкә кереп язылганнары да бар. Хәтта гарәпчә укырга төшендә өйрәнгән кеше ул. Кеше ышанмастай нәрсәне чын булса да сөйләмә, дисәләр дә, хәзерге көндә беркайда да гарәп телен өйрәнмәгән көе, Коръәнне гарәпчә укый ул, намазын калдырмый. Кызлыкка алган Арианналарын да берничә ел төштә күргәннән соң эзләп табалар. «Көн дә бер яхшылык эшлә» – аның яшәү девизы. Һәм шуннан рәхәтлек, канәгатьлек, илһам алып яши Рәсимә апа.

Аның өчен бүген дә яшәү мәгънәсе – туган ягы Балык Бистәсенең үсешенә өлеш кертү. Бюджет раслаганда, күрше Лаеш районында ял йорты төзеләсен белгәч тә, нигә гаҗәеп табигате булган Балык Бистәсенә дә мондый мөмкинлекләр бирелми, дип борчыла ул. Тизйөрешле поезд юллары төзелсен, ипотекага зур йортлар салынсын; яшьләр Казанга яки башка җирләргә йөреп эшләрләр иде, ди ул. Ә балалары телне, гореф-гадәтләрне үзләштереп, матур табигатьле авылда үсәрләр иде, ди.

Ул яшәгән Балык Бистәсенә терәлеп үк торган Анатышның юкка чыгу куркынычы юк, киресенчә, зураеп утыра. Юл янәшәсендә урманга әйләнеп үсеп утырган җирдә күпбалалы гаиләләргә биргән кишәрлекләрдә Казан кешеләре өйләр сала башлаган. Өч балалы гаилә ничек төзесен ул йортны, җир биргәнгә карап, аның акчасы юк бит, шуңа күрә акчалыларга саталар инде алар, дип аңлата бу хәлне Рәсимә апа.

Янәшәдә генә Түбән Тегермәнлек, Балтач юкка чыгып утыра; бер тәрәзәдә ут яна, икесендә юк, дип борчыла ул. Әгәр хөкүмәт авылларга йөз белән борылмаса, татарның тырышлыгы, гаярьлеге белән генә авылларны яшәтеп булмаячак, ди: «Авыл хуҗалыгында терлекчелекне бетерделәр. Ул кайтырга тиеш. Мәсәлән, Күгәрчендә «мәрмәр» ит җитештерү цехы бар. Ә Күгәрчен янындагы Балтач, Уракча, ике Тегермәнлек халкы нишләргә тиеш? Нигә инвестор барлык авылларда да сакламый фермаларны? Җире кирәк, халкы кирәкми, дип карарга ярамый бит ул. Игенчелек кайтырга тиеш. Игенчелек белән хәзер кайсыбер фермерлар гына шөгыльләнә. Ничек элек хөкүмәт ярдәм иткән колхозларга – шулай булырга тиеш ул».

Унике ел район хатын-кызлары берләшмәсен җитәкли Рәсимә апа. «Ак калфак»та урынбасар... «Өмет» халык фольклор ансамблендә солист. «Буш вакытыгыз бармы?» – дип сорау да урынсыз аңардан. Район газетасының һаман актив хәбәрчесе дә ул; шагыйрә буларак, төрле очрашулардан да кайтып керми.

Энергиясе, көче-дәрте, идеяләре сөбханалла диярлек аның. Хатын-кызларның хокукларын яклау буенча районнарда махсус кеше булуын да тели ул. «Мин булсам, шулай эшләр идем» дигән идеяләре шактый аның. Фикерле, гамьле, бик күпләр шикелле «юк инде, булмый инде булмагач» рәвешендә сөйләшми ул. Яхшырсын, җиңеләйсен, уңайга таба барсын, дип фикер йөртә, эшли.

Мин исә: «Менә ич алар, гади дә, гали дә Кешеләр шундый була; алар янәшәдә генә; алар ваемсыз түгел», – дип сокланам. Менә шул Кешеләрнең җан авазын ишетерлек, күтәреп алырлык башка Кешеләр дә булсын иде, дип тели күңел.

Лилия ФӘТТАХОВА

БЕРДӘН АРТЫК КИРӘКМИ

88дә дә өйләнәләр, бала алып кайтырга ашыкмыйлар... Татарстан демографиясендә тагын нинди тенденцияләр күзәтелә? Бездә гаилә институты ни хәлдә? Татарстан Министрлар Кабинетының ЗАГС идарәсе 2023 ел йомгакларына багышланган коллегия утырышы уздырды. Бу һәм башка сорауларга җавапны да шунда эзләдек.

Артамы, кимиме?

Саннарга бай коллегияләрнең берсе булды ул. Балалардан башлыйк. Узган ел Татарстанда 37 меңгә якын сабый туган. 2022 ел белән чагыштырып карасак, 0,4 процентка кимрәк бу сан. Ләкин идарә башлыгы Гөлшат Нигъмәтуллина: «Шул ук вакытта кимү темплары узган ел белән чагыштырганда сизелерлек акрынайды», – дип, артык сөендерми торган статистиканы тулыландырып җибәрде. Гади сүзләр белән әйтсәк, туучылар саны кими, ләкин элеккечә үк түгел. Элеккечә, димәктән, Татарстан Идел буе федераль округы төбәкләре арасында туучылар саны буенча быел да беренчелекне саклап кала алган.

Шул ук вакытта Гөлшат Нигъмәтуллина республикада күпбалалы гаиләләрнең артуын әйтте. Барлык туган балаларның 39,2 проценты – гаиләдә беренче, 33,6 проценты – икенче, 19,5 проценты өченче сабый булган. Калган 8 процентына дүртенче, бишенче, алтынчы балалар туры килә.

Сан

2023 елда Татарстанда **42736** үлем-китем очрагы теркәлгән. Бу 2022 ел белән чагыштырганда **5** процентка азрак.

Картаямыни соң йөрәк?..

Татарстанда яшәүче хатын-кызлар беренче сабыйларын күбесенчә 25–29 яшь аралыгында алып кайта. Укып, һөнәр үзләштереп, азмы-күпме аякка баскач ягъни. Ә 25 яшькә кадәр бала табучылар нибары 19 процентны гына тәшкил итә.

Шул ук вакытта яңа гына өйләнешкән парларның гаиләләрен ишәйтергә ашыкмавы да ачыкланган. «2022 елда, өйләнешеп, озак та үтми балаларын ЗАГСта теркәргә килгән гаиләләрнең саны 19,5 процент булса, узган ел 17 процент кына иде», – диде бу хакта Гөлшат Нигъмәтуллина.

Фикер

Ләйлә ФАЗЛЫЕВА,
Татарстан Премьер-министры урынбасары:
– Гаилә кыйммәтләрен формалаштыру һәм популярлаштыру турында сөйләгәндә, карашлар белем бирү системасы һәм ата-аналарга таба юнәлтелә. Бүген һәр мәгариф учреждениесеннән ата-аналар белән берлектә Россиядә яшәүче һәркем өчен кирәк булган гаилә кыйммәтләрен формалаштыруны көтәләр. Ә бу исә гражданлык дәресләре, «Мөһим сөйләшүләр», сөйләшү-аралашуга корылган ата-аналар җыелышлары, гаилә дәресләре аша эшләнә.

Яңа гына өйләнешкән парлар турында сүз чыккан икән, бу җәһәттән санлы күрсәткечләргә дә күз салыйк. Узган ел Татарстанда 25,2 мең пар никахларын рәсмиләштергән. Кызганыч, әмма 2022 ел белән чагыштырып караганда, монда да кимү күзәтелә. Ул чорда яңа гаиләләр саны 27,4 мең булган.

...булса да сәбәпләре

Татарстандагы демографик хәлне 25,2 мең кавышуга 14,2 мең аерылышу туры килү дә боза. Ике ел рәттән аерылышучылар саны 2,1 процентка кими, дисәләр дә. Бу проблеманы коллегия утырышында катнашкан Татарстан вице-премьеры Ләйлә Фазлыева аерып әйтте.

– Ничек кенә карасак та, бу – зур сан. Без моңа ничек тә булса йогынты ясарга тиеш. Әлеге процессны туктатуга, гаиләләрне саклап калуга бөтен көчебезне куярга кирәк, – диде ул.

Илдар Мөхәммәтҗанов
Узган ел туй иткән иң өлкән кияүгә (Әлмәт) 88 яшь булса, иң өлкән кәләш (Казан) 81 яшен тутыргач кияүгә чыккан.

Коллегиядә тагын бер кызыклы мәгълүмат яңгырады. Баксаң, Татарстан судлары гаиләләрен таркатырга җыенучы парны «читтән торып» кына елдан-ел азрак аера икән. Гади телгә күчерсәк, аерылышу процессы елданел катлауландырыла. Ләкин хәзер аерылышу турында гариза тапшыруга килеп терәлгән парларны ул авырлыклар гына куркытыр микән?

Сан

Аерылышу очракларының **30** проценты гаилә тормышының **5–10** елына, **22** проценты **15** һәм аннан да күбрәк елына туры килә.

Бер, әмма берәгәйле булсын

Татарстанда никахсыз яшәү популяр түгел. Татарстан Фәннәр академиясенең Гаилә һәм демография үзәге башлыгы, социология фәннәре докторы Чулпан Илдархановaның күпсанлы тикшерүләргә нигезләнгән чыгышында әнә шундый мәгълүмат яңгырады.

– 2022 елгы халык санын алу нәтиҗәләреннән күренгәнчә, гаилә кору яшендәге хатын-кызларның яртысы һәм ир-атларның 60 проценты никахта булган. Никахларын рәсмиләштерүчеләрнең саны Россия буенча уртача саннан күбрәк, – дип аңлатты ул.

Моннан тыш, Татарстанда икенче, өченче һәм тагын ничәнчедер мәртәбә өйләнү һәм кияүгә чыгу да популяр түгел. Әйтик, авылда яшәүче ир-атларның – 23, хатын-кызларның 25 проценты гына тагын бер кат гаилә корган. Шәһәрдә яшәүче ир-атларның 31 проценты кабат өйләнгән, ә хатын-кызларның 32 проценты кабат кияүгә чыккан.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

«Татар-информ»

ТӘРТИПЛЕ КОНЦЕРТ

Мәдәният дөньясында

Үткән белән көткән арасындагы күпер. 26 гыйнварда «Чулпан» мәдәният үзәгендә узган «Кабатланмас моңнар» тамашасын кыска гына итеп әнә шулай тасвирларга булыр иде. Ул күперне «Тәртип» радиосы салды. Максат-миссияләре дә әнә шулай яңгырый «тәртип»леләрнең. Шигырьгә салынган, елаткан һәм җырлаткан концертны без дә күреп кайттык.

Җомга киче. Атна буе көндәлек мәшәкатьләр эчендә кайнаган халык концертка ашыга. Араларында дөньяны артык кумый гына, үз көйләренә яшәүче әби-бабайлар да байтак. Аз булса да, яшьтәшләр дә күренгәли. «Афишада электән яраткан артистларымны күреп киләм», – диешә кайберәүләр. «Клара Хәйретдинова, Гөлзада Сафиуллина, Зөһрә Шәрифуллинаны тагын кайда ишетер идем әле», – дигәннәре дә колакка чалына. Концертның нинди рухта узачагы залга кергәнче үк шәйләнә башлый...

«Чулпан»га килеп керүгә, «Риваять» этно-төркеме каршы алды. Концерт башланыр алдыннан һәм тәнәфес вакытында җырлатучылар, биетүчеләр, уйнатучылар һәм матур көйләр тыңлатучылар да алар булды.

Концертның үзенә күчсәк, яшь һәм урта буын җырчылары – Илгиз Мөхетдинов, Гөлназ Асаева, Алсу Сәйфуллина, Айгөл Гардисламова, Рөстәм Асаев, Илшат Вәлиев, Рәсим Низамов һәм башкалар Зөһрә Шәрифуллина, Гөлзада Сафиуллина, Клара Хәйретдинова кебек танылган шәхесләр белән бер сәхнәдә чыгыш ясады. Бер төркем гармунчылар гына да ни тора! Беренче бүлек Харрас Әюпнең «Көй эзләү» поэмасына нигезләнгән иде. Илфак Хафизов укыган өзекләрдә көй эзләүче гармунчы татарның күңел халәтен, үткәнен, киләчәген моңлы җырлар белән үреп тамашачыга җиткерә алды. Җырларның да кушылып җырлый яки... елый торганнары! Тамчы да арттырмыйм. Рөстәм Асаев: «Үз ягыма кайтсам, җиргә ятып / Эчәр идем чишмә сулары...» – дип моңланганда, кулъяулык читләре белән күз яшьләрен сөртүчеләр шактый күренде залда. Ә янымдагы бер әбекәй концертның башыннан ахырына кадәр диярлек елап утырды.

– Авылымны калдырып китәргә туры килде. Элек бу җырларны радиодан тыңлый идем. Иртән чәй эчкәндә дә, бабам белән аш ашаган арада да... Авылны да, бабамны да шундый сагындым! – дип уртаклашты ул тәнәфес вакытында. Инде биш ел Казанда улларында яши икән Фаимә әби.

«Кабатланмас моңнар» – 3 сәгатьлек концерт кына түгел, тулы бер проект. Аның барлыкка килү тарихы турында «Тәртип» радосының баш мөхәррире Ризәлә Исмәгыйлева сөйләде.

– Радиода Наилә апа Яхинаның «Кабатланмас моңнар» тапшырулар циклы бара. Ул күренекле шәхесләргә, күбесенчә, арабыздан киткән композиторлар, шагыйрьләр, җырчыларга багышлана. Уйлаштык, киңәшләштек тә яңа сезонны шул ук исемдәге проект белән ачарга карар кылдык. Беренче концертыбыз 22 сентябрьдә узды. Безнең бит арабызда йөреп тә, игътибар җитмәгән, тиешенчә кадер-хөрмәт күрмәгән шәхесләребез бар. Нишләп әле алар белән бергәләп матур итеп эшләп карамаска? Яшерен-батырын түгел, концерт эшчәнлеген башлаганда, акча эшләүне дә максат итеп куйган идек. Ләкин сәхнә артында ул өлкәннәрнең ничек итеп аралашканын, бер-берсен күрергә зарыкканын, яшьләргә җиткерәсе фикерләренең күп булуын күргәч, ул максат үзеннән-үзе икенче планга күчте. Без бит үзебезне үткән белән көткән арасында күпер салучылар дип атыйбыз. Һәм бу – коры сүзләр генә түгел. «Тәртип» радиосының эшчәнлеге шуңа нигезләнгән. Кемгәдер хисап тоту өчен генә эшләнми бездә эшләр. Кешелек кыйммәтләре, кеше кадере беренче урында булырга тиеш. Эфирдагы тапшырулар, җырлар да шул принципка нигезләнә. Концертлар да шулай ук, – диде ул.

Без тамаша кылган концертка сценарийны Илнур Фәйзрахманов язган.

– Режиссер эшен Илфак Хафизов, Айгөл Нәбиуллина һәм мин бергәләп эшлибез, – диде Ризәлә Исмәгыйлева. Без аннан концертта яңгыраган җырларны ничегрәк сайлаулары турында да кызыксындык. – Җырларга килгәндә, аларны үзем сайлыйм. Худсовет кирәк, дибез бит әле. Сүз дә юк, кирәк ул, ләкин гомер буе радио-телевидениедә эшләгән кешенең башында, йөрәгендә утырырга тиеш ул сиземләү, халыкның күңел таләбен тою. Билгеле, барысы да без уйлаганча булып бетмәскә дә мөмкин. Әйтик, өлкән җырчыларыбыз яшьрәк чакта җырлаган, без яраткан җырларын башкара алмаска да мөмкиннәр. Барысын да исәпкә алып, аңлашып, эчтәлегенә туры китереп эшләргә тырышабыз.

«Кабатланмас моңнар» концертының чираттагысы 17 апрельдә Г. Тукай исемендәге Дәүләт филармониясендә узачак. Ул исә радионың 10 еллыгына багышланачак.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Борчыган мәсьәлә

Үскәч соң була

КАЗАНДА БЕРЕНЧЕ ТАПКЫР ҖЕНСИ ТӘРБИЯГӘ БАГЫШЛАНГАН ФОРУМ УЗДЫ

Бала белән ул хакта ачыктан-ачык сөйләшү гадәте юк бездә. Ата-аналарның күбесе моңа «үскәч белер әле» дип кул селти. Бу четерекле мәсьәләдән мәктәп тә ерак тора. Сүзебез җенси тәрбия турында, билгеле. Гаилә елында белгечләр гомер буе аксый килгән әнә шушы мәсьәләгә дә ныклап алынырга булган. Шул максаттан Казанда «Катлаулы сорау турында гади генә» дип исемләнгән беренче илкүләм форум узды.

Форумны оештыручы – Россия Дәүләт Думасы депутаты Айрат Фәррахов сүзләренә караганда, әлеге чара, дөрестән дә, катлаулы әйберләр турында гади генә сөйләшүне күздә тота.

– Мондый форум уздыру турында фикер Дәүләт Думасында абортларны кисәтүгә багышланган утырыш барышында туды. Бала ата-анасыннан сорарга кыенсынган сораулар бар. Ата-ана баласы белән ачыктан-ачык сөйләшә алмаган мәсьәләләр була. Еш кына мөгаллимнәр – табибларны, табиблар мөгаллимнәрне аңлап бетерми. Форумда аларның барысына да бер мәйданда фикер алышырга мөмкинлек булдырыла, – ди депутат.

Казандагы билгеле шәхси клиника җитәкчесе Адилә Зәкиева бала белән җенси мөнәсәбәтләр турында сөйләшүне аның гади генә сорауларына җавап бирүдән башларга кирәк дип саный.

– Алар, гадәттә: «Балалар каян барлыкка килә?» – дип кызыксына. Күп кенә ата-ана бу сорауны ишеткәч, югалып кала, бу хакта ачыктан-ачык сөйләшергә ояла. Әмма бу киртәне җиңәргә кирәк. Бала бу хакта беренчеләрдән булып яшьтәшләреннән яки интернеттан түгел, сездән ишетергә тиеш, – ди белгеч.

Россиянең гениталь инфекцияләр һәм неоплазия буенча ассоциация президенты, акушер-гинеколог Светлана Роговская фикеренчә, бу мәсьәләдә җенси юл белән күчә торган инфекцияләргә дә зур игътибар бирергә кирәк. Рәсми саннардан аңлашылганча, бүген республикада 100 мең кешегә 386 ВИЧ очрагы туры килә һәм әлеге сан елдан-ел арта гына бара.

Соңгы арада республикада кыз балаларның саулыгы да какшый төшкән. 7 нче номерлы шәһәр хастаханәсе баш табибының акушерлык һәм гинекология буенча урынбасары Татьяна Шиһабетдинова сүзләренә караганда, яшүсмер кызлар арасында бүген җенес органнары ялкынсыну (52 процент) һәм күрем циклы бозылу (41 процент) очраклары аеруча еш очрый икән. Соңгысы буенча рәсми саннар моннан биш ел элек теркәлгәне белән чагыштырганда шактый күп.

Белгечләр абортлар мәсьәләсенә дә тукталды. Мәскәүдән килгән тәҗрибәле табиб-гинеколог Светлана Роговская иң элек залда утырган ничә кешенең абортларны хуплавы белән кызыксынды. Форумда катнашкан 400гә якын кеше арасыннан нибары өч кул күтәрелде.

– Ә менә без, гинекологлар, моңа бишкуллап каршы. Ник дигәндә, без барыбыз да – тере җаннар. Тормыш булгач, теләмәгән йөклелек очраклары да булачак. Хатын-кыз барыбер аннан котылу юлларын эзләячәк. Шул рәвешле криминаль аборт очраклары артачак. Бу исә хатын-кызлар арасында үлем-китем очраклары күбәя, аның саулыгы да гомерлеккә какшап калырга мөмкин дигән сүз, – ди табиб.

Белгечләрнең җан авазын ишеткәннәр булса кирәк. Якын арада мәктәпләрдә гаилә нигезләре фәне дә укытыла башлаячак. Ул җенси тәрбиядән алып гаилә кыйммәтләренә кадәр барлык четерекле мәсьәләләрне үз эченә алыр дип көтелә. Россия Дәүләт Думасы депутаты Татьяна Ларионова сүзләренә караганда, әлеге дәрес Гаилә елында тормышка ашырылачак чаралар планына кертелгән инде. Ул факультатив рәвештә укытылачак.

Айрат Фәррахов тагын бер тәкъдим ирештерде. Депутат фикеренчә, балаларны, гаилә нигезләре турында сөйләп кенә калмыйча, яшәү барышында туган низагларны да чишәргә өйрәтергә кирәк. Ларионова, үз чиратында, бу тәкъдимне Думада яңгыратырга сүз бирде.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

dzen.ru

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА
РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru



ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

Гаилә истәлекләре

КЫЗЛАРГА КИЛЕШМИ УЛ

Нәни абый кечкенәдән бик хәрәкәтчән, кызыксынучан, бик башлы, укымышлы, белемле булды. Арабызда иң күп китап укучы да ул булгандыр, мөгаен. Шахмат, шашка уйнарга да ул өйрәтте мине. Иске китап тышыннан үзе ясаган шахмат тактасында. Пешкалары – тегү җепләреннән бушаган икегә бүленгән агач кәтүкләр. Шуларның яртысы каләм мана торган кара савытыннан алынган бишни буяуга буялган. Домино уйнарга да ул өйрәтте. «Мәхрүшкә тибәргә» (русча «махрушка» булгандырмы инде, шуны бозып әйтүме, белмим; уртасына ниндидер авыр тимер кисәге беркетелгән озын йонлы кечкенә генә тире кисәген бер аяк белән җиргә төшермәскә тырышып, өскә таба типкәлисең) генә өйрәтмәде. «Кызларга килешми ул», – дип әйтә иде… Ә инде футбол, волейбол уйнаганда ул иң җитезе, иң яхшы уенчы иде.

СОҢГЫ ҖЫР…

Абыем арабыздан 2010 елның 12 апрелендә китеп барды… «Без – Тукай якташлары» соңгы җыры булып чыкты. 8 апрель көнне «Арча егетләре» ансамбле белән шул җырны яздырырга Казанга, радиога килгән иде. Мин аның белән компрессорлар заводы тирәсендә очраштым. Миңа күчтәнәчләр алып килгән иде. Хәтерлим: абыем белән саубуллашып китеп бардым да, кире килеп, ул автобуска кереп киткәнче кабат кочаклашып саубуллаштым… Нигә алай эшләгәнемне аңлата алмыйм… Гомумән, гаҗәп хәлләр булды. 12 апрель көнне иртән эшкә барам. Абыем шалтырата. «Нихәл, сеңлем», – дигәне аңлашылды. Тагын әйтә башлый, тагын аңлашылмый. Аннары телефон тынды. Мин: «Абыем, абыем!» – дип карыйм, җавап юк… Автобустан төштем дә юлдан ераккарак, тынычрак җиргә, өйләр арасына кереп, тагын шалтыраттым. Берничә тапкыр. Җавап булмады. Булгалый иде телефоннан сөйләшә алмаган вакытлар, соңрак шалтыратып сөйләшә идек. Берәр эше килеп чыккандыр, шуңа сөйләшеп булмыйдыр дип уйлап, автобуска утырып, эшкә киттем. Кабат шалтыратам дип торганда, Айдар энем шалтыратты. Хәбәрен җиткерер алдыннан мине «әзерләргә» керешүгә үк, мин: «Абыем?!» – дип кычкырып җибәрдем… Миңа шалтыраткан чагында газиз туганымның дөньядан китеп барган минутлары булган…

Фәрдия СӘФӘРГАЛИЕВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

Ак кыш

Яратам мин ап-ак төсне,
Бөтен дөнья ап-ак төсле.

Куяннар да ак тун кигән,
Каеннар да ак туннан.

Бүреккә дә, керфеккә дә,
Борынга да ак кунган.

Шундый якты, шундый нурлы,
Бөтен дөнья ак кына…

Ап-ак була белә шулай
Безнең туган як кына.

Роберт МИҢНУЛЛИН

МӘШҺҮР ХӘКИМ АБЫЙ

Бик күпләрнең, әйтик, кемлекләрен
Еллар буе белми барасың.
Кинәт бер вакыйга уртасында күреп,
Аның кемлегенә хәйран каласың.

Һади Такташның әлеге шигъри юллары күңелдә әткәмнең бик якын ахири дусты Хәким абый турында истәлекләрне яңартты. Инде күптән арабызда булмаса да, ничектер әле бүген дә һәрчак үзенә җәлеп итүче килеш-килбәте белән җилкапкадан кайтып керер кебек. Үзе ул гомер буе СССР илен аркылыга-буйга кичеп, елга бер әткәй янына букча кадәр китапларын күтәреп керер иде. Ул чаклардагы гадәт буенча, берәү булса, градуслы сыйланыр нәрсәсен чыгарып куяр, ә Хәким абый исә Сервантесның «Дон Кихот»ын, Бальзакның берәр романын. Әткәй дә, әлбәттә, китаплар укырга бик һәвәс, тик мондый исемдәгеләрне түгел. Хәким абый белән авыл хәлләре турында гәпләшәләр дә шул маҗаралы китапларның эченә кереп китәләр, ә мин, үсмер малай, аһлар итеп, дөньямны онытып тыңлап утырам, гәрчә күбесен аңлап җиткермәсәм дә. Һәм ул китапларын бездә калдыргач, әнкәй укый-укый да кызык итеп сөйләп җибәрә. Алга таба, бәлкем, «Дон Кихот»лар алып кайтучы Хәким абый истә дә тормас иде, әгәр инде университетта укый башлагач, чит телләр әдәбиятыннан зачет-имтихан бирергә булмаса. Менә шунда Хәким абыйны тыңлаганнарым ярдәмгә

«ВТ» архивыннан / Дмитрий Бунтуков

килде дә инде. Зачеткама уңай билге куелганын күрүгә үк, аның заманында никадәр укымышлы икәнен сагынып, чиксез сәламнәр әйттем.

Әйе, гаҗәп кызык та, җырчы кеше дә иде әле Хәким абый Фазлыяхмәтов. Бервакыт бу Владивостокка барып чыга да, илдә дефолт чоры буламы шунда, төзелештә хезмәт хакын бирүне айларга сузгач, кесә ягы саега һәм ресторанга керә дә арзанлы гына өстәлгә утыра, үзен татар җырчысы итеп таныта. Фикус гөле артына качып, «Баламишкин», «Рәйхан», «Сарман»нарны сузгач, үзен, «О-о, татарский певец!» – дия-дия, озак алкышлыйлар.

Шуннан соң туры авылыбызга кайта да туган йорты нигезендә төпләнеп, колхозның төзелеш эшләрендә таныла. Аның маҗараларын бүген дә сагынып сөйлиләр.

Әсгать СӘГЫТДИНОВ.
Азнакай районы Югары Стәрле авылы

«Чутыр-матыр»

Хөрмәтле укучыларыбыз!

Мөхтәрәм шәхесебез Харис ага Салихҗан «Һич онытасым юк» сәхифәсендә дөнья күргән «Әтием нәсыйхәте» дип исемләнгән язмасында («ВТ», 8 ноябрь саны) әкренләп кулланылыштан төшеп бара торган сүзләргә борчылуын белдергән иде. Шул ук вакытта ул, онытылып бара торган әйтелешләрне яңартып, редакциягә язмалар юлласагыз иде, дигән теләген дә җиткерде. Сабадан Мәгъдәнур Гатауллин язмасы – шуңа авааздаш.

Йомгалак урамы аша безнең Чулпыч авылы турысыннан туп-туры кисеп чыккан юл бар. Бу юл урамны кварталларга бүлә. Безнең як халкы аны квартал дими, «туры фартал» дип йөртә. «Фартал» үзебез өчен генә булса да матур яңгырашлы ич.

Сугыштан соңгы еллар. Әниләр, әбиләр сөйләшә: «Фәлән кеше вашпиталдә ятып чыккан», – диләр. Вашпитал дигәне госпиталь була инде.

Авыл апаларында «гаҗиз булдым бу кешедән» дигән сүзләр дә бар иде әле. Бу инде әлеге адәмне күралмау дәрәҗәсенә җиткәнне аңлата.

Тагын бер бик популяр сүз – «упшым». Анысы урысларның «в общем» дигәненнән.

Аш-су осталарын күп җирдә «пешекче» дип атыйлар. Ләкин минем бу сүзгә күңелем ятмый. «Аш-су остасы», – дип әйтүгә җитәме соң инде! Пешекче ул күбрәк пешегү дигәнгә ишарә ясый.

Апас якларында булганда, «пешектермә әле» дип әйтүләрен дә ишеткәнем булды. Хисләнеп, сүзләрне мулрак сибә башласаң, «пешектермә инде» дип куялар. Иң көчле тынычландыру сүзе исә Әлмәндәр картныкы – «чутыр-матыр». Монан да үтемлерәк итеп бирәү дә әйтә алмас.

Мәгъдәнур ГАТАУЛЛИН

Шигъри хисләр

Үкенмимен

Үкенмимен бу дөньяга
Килгәнемә һич кенә дә.
Туган якның якынлыгын
Тоеп үстек кечкенәдән.

Табигатьнең олы хисен
Яшермәде дөнья бездән.
Колач җәеп йөзеп киттек
Тормыш дигән зур диңгездән.

Сагынып кайтып керергә
Җанга якын төбәгем бар.
Шушы җирдә бөдрәләнеп
Үскән каен-имәнем бар.

Туган ягым, һәр каеның,
Талың якын күңелемә.
Һич кенә дә үкенмимен
Бу дөньяга килгәнемә.

Кыш күлмәге

Мин яраткан сары төсләр
Кар астында калды, күмелде.
Туен көткән яшь кәләштәй, дөнья
Өр-яңа ак күлмәген киде.

Вакыт җиткән. Кыш юрганын япкан.
Күмелгән шул көзге матурлык.
Үткәннәрне дә каплый ул юрган,
Кире кайтырга шул юллар юк.

Рәмзия ХӨСӘЕНОВА.
Кукмара районы Зур Сәрдек авылы

Соклану

ӘТИ-ӘНИ ДӘ, ҖИТӘКЧЕ ДӘ

Суфия Венераны тапкач, Хәмәтнәсыйх:

– Кем? Малаймы, кызмы? – дип сораган.

Суфия аңа:

– Канаты бар, кыз! – дип җавап кайтарган.

Ул вакытта әти кеше нәрсә уйлагандыр… Билгеле, бәхетле тормыш теләгәндер. «Оябызда ни күрсә, очканында шул булыр», – дип юрагандыр.

Чынбарлыкта республикабызда үз исемен булдырган, Россиякүләм бәйгеләрдә үзен шәхес итеп таныткан Венера Хәмәтнәсыйх кызының ачышларын әтисе юраган очышларга тиңләми буламыни? Ул үз алдына куелган изге максатына, бала тәрбияләү, тел сагы кыйбласына тугры калып, тирән киңлекләрдә очуын дәвам итә. Татар теленә киртә куелган көннәрдә дә, армыйталмый, бер милләтне дә рәнҗетми, үз теленә, халкына хезмәт итә. Киләчәктә чын алмаш, кеше дигән олуг исемгә тап төшерми торган буын тәрбияләү сагында тора. Актаныш төбәгенә, ул җитәкләгән, сәләтле балалар тәрбияли торган гимназия-интернатка кайлардан гына килеп укымыйлар! Ул – алар өчен әти дә, әни дә, мөгаллим-мөгаллимә дә, директор да.

Гимназиянең бусагасыннан сафлык, чисталык, белемгә булган мәхәббәт сизелеп тора. Балаларның – укытучыларга, укытучыларның балаларга булган мөнәсәбәтен күреп таң каласың. Бу биредә эшләүче җитәкченең көчле педагог, мөгаллимә, җитәкче вазыйфасын, үз эшен яхшы белүеннән килә торгандыр. 1996 елда яңа гына Чаллы дәүләт педагогика институтын тәмамлаган яшь кенә кызның шул ук елны шул ук институтның тарих кафедрасында укыта башлавы ук – моңа ачык дәлил. Алабуганың 9 нчы мәктәбендә, 1 нче лицеенда чирканчык алган Әлки кызы төрле республикакүләм бәйгеләрдә уңышлы урыннар яулауга ирешә:

2011 һәм 2014 елларда «Безнең иң яхшы укытучы» номинациясе, 2012 елда Татарстан Республикасының 50 иң яхшы инновацион идея бирүчеләре арасында «Белем бирүдә – инновация» бәйгесе җиңүчесе, 2012 елда Казанда басылган республикакүләм «Без яшь, без сәләтле…» фәнни-практик конференциясе материаллары җыентыгының автор-төзүчесе, 2015 елда Россия Федерациясе Президентының яшь талантларга ярдәм йөзеннән оештырылган «Белем» проекты гранты иясе. Венера ханым – республиканың татар, рус, инглиз теле укытучылары катнашында уздырылучы «Гамил Афзал укулары» конференциясенә багышланган җыентыкның авторы да.

Гимназия чәчәкләргә күмелгән җәннәт бакчасын хәтерләтә. Стеналардагы мәгълүмат чаралары өч телдә тапшырыла, барысы да җиренә җиткерелгән, аңлаешлы.

Һәрбер аткан таң яшәешкә нинди дә булса бәрәкәт алып килә. Елап аваз салган сабыйның ата-анасы да нарасыен, бәхет, шатлык теләп, белгән догаларын укып, кулына ала. Ана баласының аяк, кулларын карап, бармакларын берәмтекләп санап, гәүдәсенең төгәллеген, күз, колакларын игътибар белән тикшереп чыкканнан соң кабат үз дөньясына чума. Сабыен хыялында тәпи атлата. Сабыеның киләчәге, алдагы тормышы ничек булыр? Бәхетле булырмы? Тормышны ничек корыр? Юлында бәхеткә күмәрдәй ярын табармы? Кыз туса, бәхетле ана булырмы?

Әлбәттә, 1974 елның 22 гыйнварында Әлки җирендә яшәгән Суфия ханымның да уй-кичерешләре шундый булгандыр.

Ана өчен үз сабыеннан да Җир йөзендә иң матуры, иң йомшагы, иң акыллысы була алмыйдыр.

Суфия ханым кызын кулына алгандыр, маңгаеннан үпкәндер. «Сәламәт бул, балам», – дигәндер. Ул аның уң ягыннан үпкәндә: «Бәхетле бул, балам», – дигәндер. Сул яңактан үбеп: «Озын гомерле бул, балам», – дигәндер. Әмин! Без дә шул теләкләргә кушылабыз. Күзләреннән үпкәндер дә: «Балаларыңның балалары бәхетле булсын, балам», – дигәндер. Әмин! Аллаһы Тәгаләнең «Әмин» дигән чагына туры килеп, ананың теләге кабул булгандыр. Бу яңа туган баланың балалары республикабызда йөзәрләгән, меңәрләгән якты, матур уку йортларында белем алалар. Үзләрен бик бәхетле саныйлар. Шуны күрер, шуңа инанып өчен Актанышка барырга кирәктер.

«Ана сөте белән кермәсә, тана сөте белән кермәс» дигән гыйбарә бар. Ана күкрәген баласына бирер. Сабыйның иреннәреннән нәни яңагына агып төшкән сөт, елга булып, аның күз алдында муенына, гәүдәсенә, җанына, яшәешенә юл алыр.

Ана, мөлдерәмә яшь тулы күзләре белән сөт елгасына карап:

– Ак юл, хәерле сәфәр сиңа, балам, – дияр.

Язма нәкъ шундый уйлар, хисләр кичергән Суфия ханым белән Хәмәтнәсыйх туганыбызның уртак никахында дөньяга килгән, бүген Актаныш районының Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернат директоры, чын ана, көчле мөгаллимә Венера Хәмәтнәсыйх кызы Хәева-Хәмәтҗанова турында булыр.

Казанны биш бармагы кебек белгән Максим Горький, татарлар яши торган якка, Яңа бистәгә күрсәтеп:

– Матурлыкны, пакьлекне күрәсегез килсә, әнә теге яктан эзләгез, – дигән.

Татарның матурлыгын, чисталыгын, телен, гореф-гадәтләрен, үткәнен, бүгенгесен күрәсегез килсә, нәкъ Максим Горький әйтмешли, Венера Хәмәтнәсыйх кызы җитәкләгән гимназиягә тукталырга кирәктер. Татарның кыйбласын дөрес ракурста тоткан бу белем йорты әйтеп-аңлатып булмаслык көчкә ия булган, республикабызда гына түгел, Россиякүләм бәйгеләрдә югары күрсәткечләр белән шатландырып, төпле белем бирүче иң алдынгы гимназияләрнең берсе итеп гамәлгә куела. Болар барысы да – укучыга белем бирүдә ачыктан-ачык ярдәм итү чараларының гүзәл мисалы.

Гимназиядә милләтебезнең мәшһүр җырчысы, Актаныш кызы Әлфия Авзаловага багышланган музей, Г.Тукай премиясе иясе, шагыйрь Мөхәммәт Мирза исемендәге поэзия кабинеты бар. Гимназиядә шәхсән үземнең дә драматургия кабинетым булдырылды. Болар – Венера ханымның тынгысыз, ял белми торган җанының бер авазы. Бу көннәрдә аңа 50 яшь тулды. Киләчәктә дә очар киңлеге иркен, канатлары нык булсын!

Данил САЛИХОВ,
Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе

Тылсым чыганагы

Авыл башыннан бик матур тавыш ишетелә – чишмә челтери! Мин бу челтерәүне гомер-гомергә үз итәм һәм шул тарафка юнәләм. И газиз чишмә, суың кимеп бара икән шул инде, әмма челтерәвең гел элеккечә! Шул авазың белән ниләр әйтергә телисең икән? Яңа туган бала кебек елыйсыңмы, әллә җырлыйсыңмы? Нишләсәң дә, син дөньяны бизәдең, зур юлыңны башладың, суың еракларга барып җитә. Әйе, синнән башка зур елгалар булмас иде, хәтта океаннар да кибеп бетәр иде. Чишмәләргә безнең халык гомер-гомергә тылсым чыганагы буларак караган. Чишмә суы яшәткән безне. Кадерле кунак килгәндә, хуҗабикә чишмә суыннан чәй куйган. Килен төшкәндә, аңа чишмә юлын күрсәткәннәр, чөнки иң пакь су монда – чишмәдә, димәк, гаилә юлы да шундый пакь булырга тиеш. Чишмә янында яшьләр вәгъдә бирешкән. Озак еллар чит-ят җирләрдә йөргән кешеләр дә, авылларына кайтса, чишмә буена килгәннәр. Ил-көн имин, тормыш мул, тән сәламәт, җан тыныч булсын өчен, чишмәләргә көмеш тәңкәләр салу гадәте дә булган.

Чыннан да, без чишмәне серлелеге өчен яратабыз, аңа тартылабыз. Серле күкләргә, серле йолдызларга серебезне чишәбез, садә хисләребез белән уртаклашабыз. Чишмәләр шул вазыйфага тартыла. Чишмәләребезнең елдан-ел матурая, илһамлана баруы күңелебезгә бәрәкәт өсти. Үткәннәрне барлау, хәтер яңарту, киләчәккә өмет баглау өчен киләм, киләм әле мин сиңа, Чишмә!

Заһит МУРСИЕВ.
Башкортстан

Хөрмәтле укучыларыбыз!

Өлкәннәргә дә, яшьләргә дә мөрәҗәгать итүебез: нәкъ менә балачактагы хатирәләрне күңелегездә яңартып, «Һич онытасым юк» сәхифәсенә язмалар юллагыз әле. Үзегезгә үткәнгә кайтып килү булса, башкаларга соклану, йә булмаса гыйбрәт алу булыр.

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Кеше кайгысы түгел

Тормышыбыз түгәрәк инде безнең, тик хәзер кеше кеше белән аралашмый, үзенә бикләнде, анда кеше кайгысы юк. Шулай дибез инде. Моңа артык исебез дә китми бугай, тик көндәлә нәрсәнедер юксыну тойгысы да чалынып калгандай була. Аралашу бик юк бит инде, чынлап та.

Кешенең аралашып яшәвен күрсәтү өчен иң уңайлы җир тулай торак бугай. Исеменнән үк билгеле бит инде, монда кеше уртак тормыш кичерә. Бу гомерендә берләрсә дә эшләмәгән ата ялкаулар һәм пошмас кешеләр яңадан туарга тиеш. Тулай торак бүлмәсенең ишеге булып. Чөнки аңа бер мизгелгә дә тынгылык бирмиләр, гел тәртәкләп торалар – әле анысы килеп шакый, әле монысы. Кайберләре шакып тормыйча гына бәреп керә. Кайберләре ишекне ачып кына карый да, күзе кызыгырлык нәрсә тапмыйча, ары китә. Кемдер хәл белергә керә, кемдер үз хәлен белдерергә. Кемдер тоз сорый, кемдер суган, кемдер бәрәңге... Шуңа күрә тулай торакта кеше беркайчан да ачтан үлә алмый, өчдүрт бүлмә ишеген шакыдыңмы – ашар ризык табыла.

Элек авыл да, кала да – барысы да үзара керешеп, йөрешеп, бер тулай торак шикелләрәк яши торган иде. Шуңа тормыш агышын тою җайлы, чөнки ул бер мәйданга җыелган халык шикелле шау-гөр килеп тора. Хәзер тормыш алай шауламый, ул өстәлгә менгән мәче шикелле шым гына ага. Шундый ук шым һәм житез. Кайчагында аның бармы-юкмы икәнен дә тоймый каласың, бары тик өстәлдәге май савыты бушаганны күреп кенә барысын да чамалыйсың. Гомереңнең бу чоры да үзып киткән икән ләбаса, дисең.

Аралашып яшәүнең сәбәпләре күптер инде аның. Тик иң мөһиме мохтаҗлык бугай. Бүтәннәрдән сиңа нәрсәдер кирәк булу. Тоз кирәк икән – ишек кагасың, кыз кирәк икән – тагы... Өметең тәмам өзелгәнче шулай йөреп була. Ә ул өзелми, бер ишектән тапмаганыңны икенчесеннән мәҗбүри биреп җибәрәләр.

Әгәр сиңа берни дә кирәкми икән, беркемгә дә барып йөрмисең. Ашар ризык, кияр кием бар, сөйләр яр янәшәдә, телефон тулы дуслар, гап күерту ихтыяҗы юк, бөтен нәрсә бар – шулай булгач, кая барып, нәрсәгә өметләнеп йөрисең инде. Ятасың өендә, кемдер сораныл килгәнне көтеп. Ә ул килми, чөнки үзе дә синең хәлдә. Һәм зарланырга мәҗбүр буласың: кеше үзенә бикләнде хәзер, дисең.

Үз көнен үзе күреп яшәүченең аралашуга артык мохтаҗлыгы булмый. Ә мохтаҗлык булса? Үз-үзеңне хәстәрләрлек хәлдә булмасаң? Ул чакта инде, чынлап та, ишекләрне җилтерәтеп йөрергә кала. Син барысын да күрәсең, барысына да керәсең. Ә үзеңә берәү дә килми. Беркем дә килми икән, димәк, аларга синнән берни дә кирәкми. Ә сиңа кирәк... Шунда аңлыйсың инде үзеңнең нинди хәлдә икәнеңне. Хәер сорап йөргән фәкыйрь кебек бит инде бу, теләнче шикелле. Һәм син үзең дә алар дәрәҗәсенә күтәрелергә, арт шәрифеңне аларныкы шикелле йомшак җиргә утыртырга тырышасың.

Бу бик җиңел түгел икән. Ләкин акрынлап кына нәрсәдер килеп чыга, мохтаҗлыкларың кими бара. Аның саен күңелең үсә, ныграк тышысаң, нәтиҗәсе яхшырак булыр дип уйлыйсың һәм тырышасың. Хәзер инде син башың белән мәшәкатькә, эшкә чумасың, кем беләндер аралашырга теләгең булса да, вакытың калмый. Вакыт табылса, теләк югала. Шундый авырлык белән ялганган бераз буш вакытыңны әлә кемнәргә әрәм итә алмыйсың ич инде, аны ял итүгә багышларга кирәк. Башка чараң да юк, арыгансың, талчыккансың. Хәзер ял итеп калмасаң, берәздан тагын тынгысыз чор башланачак...

Ә бүтәнчә булмый. Син үз тормышыңны фәкать үзең генә көйли аласың. Бүтәннәрдән ярдәм көтә алмыйсың. Якын кешеләреңнән – биграк тә. Чөнки алар да нәкъ үзең шикелле үк, үз тормышларын җайга салу белән мәшгуль һәм бер минут вакытлары да буш түгел. Хәзер инде син яхшы аңлыйсың, кешенең вакытын алу ул аның акчасын каерып алудан да хәтәррәк, чөнки акчаны кире кайтарып биреп тә була, ә вакытны – юк. Иң явыз карак, иң яман талаучы – кешенең вакытын алучы. Һәм син фәкать үзеңә генә ышанып, үз тормышың белән генә яши башлыйсың. Бүтәннәр белән аралашуга инде ихтыяҗың да бетә, вакытың да калмый, кызыгы да югала.

«Тормышы түгәрәк», – диләр бит инде мохтаҗлыгы беткән кеше турында. Безнеке дә шулай – шар кебек. Һәм без шул шарны тәгәрәтеп, таугa менеп барабыз. Һәркемнең – үз шары. Күршесенә ярдәм итәр иде, үзенеке аска төшеп китәчәк. Ярдәм сорар иде, кулын кесәсенә тыгып торган буш кеше юк. Һәркемнең – үз шары. Һәр шарның – үз авырлыгы.

РУШАНИЯ НИЗАМОВА:
«КЫЗЫК ХӘЛЛӘРНЕ ЭЗЛӘП ЙӨРМӘДЕМ»

Әдәбият

Бала күңелен ничек аңларга? Укучыларны ничек яраттырырга? Аксубай районының Яңа Дума авылында яшәүче язучы, шагыйрә, 40 ел гомерен мөгаллимлеккә багышлаган, гыйнвар башында 80 яшьлек юбилеен бәйрәм иткән Рушания НИЗАМОВА белән әңгәмәбезне шул сораулардан башлаган идек. Үзебез дә сизмәстән, Нәҗип Думавига, аның варисларына һәм язмыш сынауларына да барып җиткәнбез...

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Роберт белән икебезнең холыклар бер иде»

:: 80 яшегезне нинди уй-хыяллар белән каршы алдыгыз?

– Хикәяләр тупланган китабымны чыгарырга ниятләгән идем дә, нәшриятта чират тимәде. Мин аны көтеп ятмыйм инде, акчамны түлим дә икенче нәшриятта бастырып кайтырга уйлап торам. Күптән түгел генә мәктәптә балалар белән очрашуда булдым. Шигырьләремне укыдылар. Күңелем тулды шунда... Шигырьләремне китап итеп туплап чыгару теләге уянды. Менә шундый матур уй-хыяллар белән яшәп ятам.

:: Сезнең «Бәхет» исемле китабыгызга кереш сүзне Роберт Миңнуллин язган. Ул сүзләрдән җылылык бөркелә. Сез аның белән яхшы дуслар булгансыз, ахры?

– Безнең кебекләр турында «җеннәре туры килә» диләр. Роберт белән без биш ел бергә укыдык. Икебезнең дә холыклар бер иде. Хатыны белән дә, әнисе белән дә яхшы мөгамәләдә булдык. Робертның иҗатын бик хөрмәт итәм мин. Балалар өчен Шәүкәт абый белән ул гына шулай яза беләдер. Кереш сүзгә килгәндә, «Бәхет» китабын чыгарганда, тагын кем язсын инде, дидем дә Робертка мөрәҗәгать иттем. Чыннан да, шундый матур итеп язган иде ул аны...

«Баланы яратырга кирәк»

:: Рушания апа, ә бала күңеленә юлны ничек табарга соң?

– Дәресләр вакытында минем бер гадәтем бар иде. Өйгә бирелгән дәресне сорагач, яңа теманы сөйләгәч, ун минут вакыт калдырам. Шунда балаларга үзләре тарыган кызыклы хәлләрне сөйләтә идем. Аларга шул җитә кала: берсен-берсе уздыра-уздыра сөйләргә тотыналар. Әсәрләремдәге кызык хәлләрне урамнан эзләп йөрмәдем, балалар үзләре сөйләгәннәрне яздым. Аларны бары тик ишетергә, күрә белергә генә кирәк.

:: Ул әсәрләрдә укучыларыгыз үзләрен таныймы?

– Танныйлар! Әсәрләремне укыганда: «Апа, без бит бу, безнең турында язгансыз бит», – диешәләр. Шулай дигәч, мин аларны мактап куям. Дәресләрем бик кызык үтә иде. Укучыларыма дус булырга тырыштым, «2ле» куймадым. Алар минем дәрескә яхшы әзерләнеп килә иде. Өй эшен тиз генә сөйләп чыккач, ахырдан укырга вакыт кала бит. Ә алар мин укыганны тыңлап утырырга бик яратты.

Балаларны яратырга кирәк. Сине яратсыннар, дисәң, син дә ярат. Бала укытучының яратуын күзеннән күрергә тиеш. Аннан соң, кеше алдында, яшьтәшләре янында аның дәрәҗәсен төшерергә, кимсетергә ярамый. Бүгенге укытучыларга әйтәсе килгән сүзем шул.

:: Язмыш сезне сындырырга тырышып караса да, бирешмәгәнсез. Улыгыз Фәнискә ана назы бүләк итеп, аны аякка бастыргансыз...

– «Балаң үле туды», – дигеләр миңа. Югыйсә бер сабыйның кычкырып елаганын ишеттем бит! Башка бала булган икән... Кан йөрешем дөрес булмагач, бүтән бала алып кайтмаска куштылар. Ул чакта нарасыемны да, иремне дә җир куенына тапшырдым... Адәм баласы түзә бит ул. Шулай 10 ел узып китте. Бервакыт балалар йорты турында язарга туры килде. Шундый йортларның берсенә килеп кергәч, сабыйлар урап алды. «Әни, әни!», «Мама, мама!» – диешәләр... Почмакта утыручы ябык кына бер малайга күзем төште. Балалар йорты директорына бардым да: «Кәҗәм бар, авылда яшим. Бу малайны бирегез миңа», – дим. Ул чакта ике ел көтәргә кирәк дигән закон бар иде. «Хәзер аласыгыз килсә, министрлыкка барыгыз», – диделәр. Шул ук көнне Казанга киттем. Ир-ат кыяфәтле бер ханымга барысын да аңлаттым. Ә ул һаман шул законны кабатлады. Шулчак тотындым еларга... Әллә кызганды, әллә башкасы шунда: балалар йортына шалтыратып, ул баланы миңа бирергә кушты.

Фәнискә ул чакта 3 яшь иде. Бик кечкенә чагыннан ук иң зур терәгем, сердәшем, киңәшчем булды ул бала. Мәктәпкә укырга кергәч, «Син балалар йортыннан кайткан», «Син әниеңнең үз баласы түгел» ише сүзләр әйткәннәр аңа, берсен дә сиздермәде шуның. Тырыш, уңган булды, бер генә кире сүз дә әйтмәде. Өч диплом алды. Бүген менә, шөкер, яратып эшен тапты: район мәдәният йортында режиссер булып эшли. Гаиләсе белән Аксубайда яши.

«Әти-әниемә никахны Нәҗип Думави укыган»

:: Сез бит әле – Нәҗип Думавиның иҗат һәм тормыш юлын да өйрәнгән кеше. Аңа бәйле тарих сәхифәләреннән кайсылары аеруча истә калган?

– Нәҗип Думави коточкыч ачлык чорында – 1921 елда – безнең авылның мулласы вазыйфаларына керешә. Ә мулла булырга аны халык күндерә. «Ачлыктан ярты авыл үлеп бетте, Аллаһы Тәгаләдән сорыйк инде», – дип ялварып ала. Нәкъ шул елны безнең әти белән әни никахлашырга карар кыла. Никах укырга Нәҗип Думави килә. «Ул бездә чакта, бер генә балабыз булса да Думавига охшасын иде, дип теләп утырдым. Үзе галим, үзе мөгаллим, үзе шигырьләр яза, белмәгән нәрсәсе юк», – дип сөйләгән иде әни. 10 баласының берсе, ягъни мин гомерем буе Нәҗип Думави укыган мәктәптә балаларга белем бирдем, балалар өчен китаплар язам. Димәк, әнинең ул чакта теләгән теләге кабул булган.

:: Аның варислары белән аралашасызмы?

– Нәҗип Думавиның 7 баласы була. Билгеле булганча, гомеренең соңгы елларын Сәмаркандта уздырырга мәҗбүр була ул. Бүген аның оныкларының-оныкчыкларының күпчелеге шунда яши. Ә өченче баласы – Чыңгызның кызы Гөлнара Тахтамышева Казанда гомер кичерә. Нәҗип Думавиның Яңа Думада узган бер генә юбилеен да калдырмады ул. Ләкин, кызганыч, күптән түгел узган 140 еллыгына гына кайта алмады. Югыйсә шундый матур китап чыгарган идем. Нишлисең, заманасы шундый бит...

Әңгәмәдәш – Лилия ГЫЙМАЗОВА

Яшәеш

АКЧА БИРЕП ТОР ӘЛЕ...

Бүген кибеткә, даруханәгә, башка сәүдә-хезмәт күрсәтү урыннарына керсәң, «Ничек түлисез, карта беләнме, акчалатамы?» – дип сорыйлар. Авылларда да карта белән түләү кереп бара. Бигрәк тә яшьләр картадан башка түләүнең ни икәнен онытты, дисәң дә була. Шуңа күрә акчалата исәп-хисап ясыйсы булса, бу инде алар өчен проблемага әйләнә.

«Акча биреп тор әле, кучерер идем», – дип эндәшергә таныш берәр өлкән кеше очраса ярый ла (әле бит өлкәннәрнең дә күпчелеге бу «мода»га – заманча яңалыкка тиз ияләште. Алар арасында да картаны үз итүчеләр күп).

Бервакыт район үзәгеннән кайтырга такси чакыртым. Яшь таныш шалтыратты да: «Онытканмын бит, Гөлсинә апа, акча күчерергә. Картагыз шушы номерга беркетелгәнме? Сбербанкмы, кайсына күчерим?» – диде. Безнең сөйләшүнең шаһиты булган таксист сүзнең нәрсә турында барганын аңлап алды.

– Нәрсә, акча күчерергәме? Хезмәтегез өчен түлиләрме? – дип сорады.

– Юк. Танышым ул. Бер чарада бергә катнашкан идек, китап сатучылар да бар иде, карта белән кабул итмәгәннәрен белгәч, миннән акча алып торган иде.

– Сатучыларның картасына гына күчереп булмады микәнни? – ди таксист. – Акчасыз йөрми алар, гадәтләре шундый, – дип дәвам итә таксист. Күреп торам: бу тема аның «бавыр»ында. – Таксига утыралар,

төшәр вакыт җиткәч, абый, түләргә акчам юк, төшкәч тә картадан күчерәм, диләр. Хәзер күчер, дип, номер бирсәң, монда интернетым юк шул, диләр. Ышанмасаң да, нишлисең инде. Алай да, өегездән алып чыгып бир, көтеп торам, дисең. Өйдә дә акча тотмыйбыз шул, диләр. Һәм шуның белән шул. Күчермиләр. Дөресме, дөрес түгелдерме, әмма мин кесәсендә ипи алырлык та, район эчендә, Балтач эчендә таксига түләрлек тә акчасы булмаган кешеләрне аңламыйм. Бүген тырышкан, эшләгән кеше акчасыз була алмый.

– Акчасыз түгелдер алар, «тере» акчалары гына юктыр, – дим. – Без тегe чор кешеләре шул. Миңа да балалар күпме, карта белән генә йөр инде, сдача да котәсе юк, акча саныйсы да, диләр. Әмма янчыгында акчам булмагач, нәрсә индe ул, дим. Картада акчам булса да, аннан түләмим, янчыктан түлим... Без шулай күнеккән.

– Картадагы акча алдавыч кына инде ул, яшьләр аны аңламый, – дип дәвам итә юлдашым. – Күпме акча тотканнарын да уйламыйлар, әле кредит карталары белән «яналар». Бушка алган кебек тоеладыр инде.

– Төрлесе бардыр. Киресенчә, бөтен исәп-хисаплары күренеп бара, айга күпме акча тотканнары да күренә, әле бонуслары да кайта... Иләнгән кешегә бик уңайлы, – дим. – Акча ваклатасы, әрәмләтәсе дип уйлыйсы түгел. Янчык күтәреп йөрисе юк...

– Безнең кебекләрне алдарга да бик уңайлы шул, – ди таксист.

– Сез утырганда ук шарт куегыз, акчалата түлисе, дип әйтегез, – дим.

– Алай булса, бөтенләй клиентларсыз калуың бар, – дип, бераз уйлана калды да көлеп җибәрде ул. – Әй, алдарга уйлаган кеше алдый инде ул, безне ышанучыруның берние юк бит... Шөкер, бөтен кеше дә андый түгел. «Сезнең эшегез бит бу, хезмәт хакыгыз бит», – диюче күп... Өлкәнрәкләр, кереп утыруга, акча янчыгын тартып чыгара, түләргә әзерләп барып ут, акча санарга керешә...

– Әһә, безнең кеше икән, дисезме? – дим. Килешә. «Алар безнең кешедер дә, тик без үзебез башкалар өчен «безнең» кеше икәнме соң?» – дип уйлап куйдым. Чорына, заманына күрә, диюем. Монысын, әлбәттә, кычкырып әйтмәдем.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 2042 данә
Гомуми тираж – 11230 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 210

РЕДАКЦИЯ һӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Кучерепу бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).
16+